МЕТОДИК ӘСБАП

# ӘДӘБИ УКУ

# 3

Г.Н.Мөхәрләмова, Д.М.Абдуллина



Г.Н.Мөхәрләмова, Д.М.Абдуллина

# ӘДӘБИ УКУ

## МЕТОДИК ӘСБАП

3

Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән
эшләүче укытучылар өчен

Казан
2023

УДК 82 (072)
ББК 74.268.3 (=632.3)
М92

Методик әсбап
Татарстан Республикасы Фәннәр академиясенең
Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият
һәм сәнгать институтында эшләнде

**Мөхәрләмова Г.Н.**

М92 Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Методик әсбап : Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән эшләүче укытучылар өчен / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. — Казан: Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе нәшрияты, 2023. — 86 б.

Методик әсбапта 3 нче сыйныфта «Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметы буенча дәреслек белән эшләү тәртибе яктыртыла. Биредә предметны өйрәнүгә куелган максат-бурычлар, предметны өйрәнүдә планлаштырылган нәтиҗәләр, тематик планлаштыру, дәрес эшкәртмәләре үрнәкләре бирелә.

Әсбап башлангыч сыйныф укытучыларына ярдәмлек буларак тәкъдим ителә.

© Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе, 2023
© Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2023
© Мөхәрләмова Г.Н., Абдуллина Д.М., 2023

# ХӨРМӘТЛЕ ХЕЗМӘТТӘШЕБЕЗ!

3 нче сыйныфта әдәби әсәрләр иҗатның чынбарлык белән бәйләнеше ягыннан өйрәнелә. Безнең өчен иң мөһиме – әсәрне анализлаудан бигрәк, укучыларга дөньяны танып-белергә, әхлакый мәсьәләләрне хәл итәргә өйрәтү. Әдәби әсәр – ул автор белән укучы арасында үзенчәлекле бер күпер кебек. Язучының фикеренә төшенеп, текстның проблемалы эчтәлеген ачыклап, укучы үзен үзе танып белүгә ирешә. Укытучы бу вакытта ярдәмче һәм юл күрсәтүче ролен үти. Димәк, әдәбият укытучысы өчен иң әһәмиятлесе – сөйләшүне укучы үз артыннан әдәбият дөньясына кереп китәрлек итеп оештыру. Укытучының укучылар белән сөйләшүе аша алар бер-берсен мәдәни, әхлакый һәм рухи яктан баета.

Укытучыдан олы хезмәт, зур тырышлык таләп итә торган рухи-әхлакый тәрбия нәтиҗәләре беренче чиратта балаларның үз-үзләрен тотышларында, аларның үзара мөнәсәбәтләрендә, иҗади эшләүләрендә, әхлакый яктан үсүләрендә, тормышка карашлары үзгәрүдә чагылыш таба. Чөнки яхшы гамәлләр кылу теләге, әхлак сафлыгы, рухи байлык балалар күңеленә мәңгелеккә кереп урнаша һәм аларда якты хисләр уята.

Әдәбият – яшь буынның рухи табигатен һәм әхлакый ориентирлар формалаштырып, укучының эмоциональ, интеллектуаль һәм эстетик үсешендә мөһим урын алып тора. Әдәбият һәрвакыт тормыш-чынбарлык белән бәйле.

Әдәби уку дәресләрендә укучыларда әхлакый сыйфатлар тәрбияләү күп очракта матур әдәбият текстлары аша алып барыла. Зур тәэсир көченә ия булган матур әдәбият әсәре укучыларның рухи аңын формалаштыруда катнаша, кешенең бу дөньяда тоткан урыны һәм роле, яшәү мәгънәсе турында күзаллау тудырырга ярдәм итә, югары хисләр тәрбияли.

Дәреслеккә кергән әсәрләр җиде кат иләк аша үткәреп сайланган, аларның һәркайсы гаять зур тәрбия чыганагы булып тора. Укытучыдан әзерлекле, эзләнүчән, иҗади якын килү генә таләп

ителә. Кеше үзендә булдырырга тиешле киң күңеллелек (яхшылык), мәрхәмәтлелек, кешелеклелек, намуслылык, гаделлек, тугрылык, тәрбиялелек, җаваплылык, эш сөючәнлек, башкаларга хөрмәт кебек әхлакый сыйфатларны тәрбияләүдә аларның роле бик зур. Шулай итеп, әдәби әсәрләр белән танышу барышында укучылар иң кирәкле әхлакый төшенчәләрне үзләштерә. Биредә укучыларның гражданлык һәм әхлакый-кыйммәти позицияләре формалаша, шуңа күрә баланың игътибарын геройларның эш-гамәлләренә һәм анда чагылыш тапкан әхлакый кыйммәтләргә юнәлтергә кирәк.

Әсәрне тормыш белән бәйләгәндә, көндәлек яшәешебездән мисаллар китергәндә, уңай үрнәкләрне генә түгел, тискәреләрен дә күрсәтеп, аларның асылын аңлату да – отышлы алым. Әдәби геройларның да, тормышта кешеләрнең дә я уңай, я тискәре типларга гына бүленмәвен истә тотканда, бу алымның әһәмияте тагын да арта. Анализ шул юнәлештә барганда, укучы нәрсәнең яхшы, нәрсәнең начар икәнлеген тизрәк төшенә. Кемнең, кайда хата яки ялгыш җибәрүен таный, ул ялгышның нәтиҗәләрен күрә. Беренче карашка әллә ни зур күренмәгән ялгышның, кечкенә генә бер гамәлнең, уйланылмый әйтелгән сүзнең кеше язмышларын хәл итәргә мөмкин икәнлеген аңлый.

Әдәби уку дәресләрендә баланың, тормыш тәҗрибәсеннән чыгып нәтиҗә ясавы яхшы. Укучы әдәби әсәр эчендәге вакыйга һәм кичерешләрне үз күңеле аша үткәрә алырга тиеш. Бала бер генә мизгелгә шул әсәрдәге тормыш белән яшәп алганда гына укуның файдасы булачак, максатыбызның шәхескә юнәлтелүенә хезмәт итәчәк. Предмет укытучысы һәрвакыт шуны истә тотарга тиеш: иң әһәмиятлесе – без укыта торган фән түгел, ә без тәрбияли торган бала шәхесе.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын 2 сәгать укыту мөмкинлеге булган очракта тәкъдим ителгән темалар икешәр сәгать өйрәнелә. Дәреслектә өстәмә материал бар.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметының төп **максаты** – татар мәдәниятенең мөһим өлеше булган туган (татар) телдәге әдәбиятка сакчыл мөнәсәбәт тәрбияләү, укучылар-

ның мәдәни мираска, үз халкының гореф-гадәтләренә тартылуын тәэмин итү, киләчәктә куелган уку бурычыннан чыгып, шулай ук үзләре кызыксынган өлкәгә караган әсәрләрне китапханәләрдән мөстәкыйль рәвештә сайлап алырлык грамоталы укучы формалаштыру.

Максатларны тормышка ашыру түбәндәге бурычларны хәл итә:

- укуга һәм китапка карата кызыксыну тәрбияләү, укучының тормышны күзаллавын формалаштыру;
- укучыларның аралашу (коммуникатив) сәләтен булдыру;
- укучыларның туган (татар) телендә телдән һәм язма диалогик, монологик сөйләмен үстерү;
- кычкырып һәм эчтән (үз-үзеңә) уку техникасын булдыру һәм камилләштерү, текстны төшенү (кабул итү һәм аңлау) алымнарын үстерү, эшчәнлекнең универсаль төрләренә – күзәтүгә, чагыштырма анализга өйрәтү;
- әдәби анализ элементларын куллану аша укучыларны сүз сәнгатенә, туган телдәге әдәбиятка якынайту, аерым әдәби-теоретик төшенчәләр белән таныштыру;
- укучыларның әхлакый һәм эстетик хисләрен формалаштыру, әсәрләрнең рухи асылын аңларга өйрәтү;
- туган (татар) телендә иҗади эшчәнлек сәләтләрен үстерү.

Укыту барышында сыйныфларда белем бирү эчтәлеге түбәндәге эшчәнлек төрләре белән үрелеп бара.

**Тыңлау.** Укытучы һәм сыйныфташлары тарафыннан кычкырып укылган текстны, әңгәмәдәшләренең фикерләрен, үзенә бирелгән сорауларны аңлау. Әйтелгән (ишеткән) сүзнең мәгънәсенә төшенү: фикер алышу аспектын тотып алу, сөйләм эчтәлеге нигезендә сорауларга җавап бирү һәм үз сорауларыңны формалаштыру.

**Кычкырып уку.** Иҗекләп укудан сүз белән укуга күчү, уку тизлеген акрынлап арттыру. Рольләргә бүлеп уку, чылбыр буенча уку барышында кычкырып уку техникасын формалаштыру. Сәнгатьле уку үзенчәлекләрен үзләштерү (башлангыч этапта җөмләләрне тыныш билгеләренә карап, интонацион буыннарга аерып, дөрес итеп, жанр таләпләренә туры китереп уку).

**Үзлегеннән уку (эчтән уку).** Күләме зур булмаган текстны мөстәкыйль уку. Өйрәнелә торган текстта кирәкле мәгълүматларны, аңлашылмаган сүзне сүзлектән табу һәм сайлап уку ярдәмендә төп мәгънәне истә калдыру.

**Сөйләү.** Монологик сөйләм төрләрен үзләштерү: сораугa кыска яисә киңәйтелгән җавап рәвешендә; текстны укудан туган үз тәэсирләрен, тормышны күзәтүләреннән туган тәҗрибәне тапшыру рәвешендә; фикерне текстка таянып дәлилләү рәвешендә (текстта кирәкле урынны табып уку). Диалогик аралашу үзенчәлекләрен үзләштерү: әңгәмәдәшенең әйткәннәрен тыңлый һәм аларга карата үз мөнәсәбәтен белдерә белү (ризалашу / килешмәү). Текст эчтәлегенә таянып, үз фикерләрен дәлилләп яклый белү.

**Язу.** Текст төрләренең аермасын тану (текст-хикәяләү, текст-тасвирлау, текст-фикер йөртү) һәм аларны кечкенә сочинениеләр формасында практик үзләштерү; шәхси күзәтүләр һәм тәэсирләр нигезендә кыска сочинениеләр язу.

**Әдәби әсәр тексты белән эшләү.** Текстның исемен анализлау, сораулар һәм биремнәр системасы аша текстны тикшерү, төп эмоциональ-мәгънәви берәмлекләрне ачыклау (төп фикер, лирик шигырьдә төп кичерешләр, геройларның капма-каршы позицияләре һәм хикәядә автор нәтиҗәсе). Текст төзелешенең үзенчәлекләрен билгеләү, тел-сурәтләү чараларын ачыклау (антонимнар, синонимнар, сынландыру, чагыштыру). Геройның холкын билгели белү (сүз ярдәмендә тудырылган портреты аша, гамәлләрен анализлаудан, сөйләм үзенчәлегеннән чыгып, автор аңлатмалары ярдәмендә), башка геройларның үз-үзләрен тотышына чагыштырма анализ, укытучы ярдәмендә проза әсәрләрендә автор позициясен һәм лирик әсәрләрдә автор кичерешләрен таба белү. Текст белән эшләгәндә, төрле сюжет сызыкларын аерып чыгара белү; эчтәлек ярдәмендә карашлар һәм позицияләрнең төрлелеген күрергә өйрәнү; сюжет үстерелешендә һәм геройларның эш-гамәлләрендә сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; автор фикерен аңлау; текстның төп фикерен аерып чыгару; тел-сурәтләү чараларын табу.

**Балалар өчен әсәрләр.** Халык авыз иҗаты әсәрләре. Фольклорның кече жанрлары (санамышлар, табышмаклар, эндәшләр);

халык әкиятләре (хайваннар турында әкиятләр, көнкүреш әкиятләре, тылсымлы әкиятләр); мәкальләр һәм әйтемнәр, мәзәкләр. Автор әкиятләре, мәсәлләре, авторларның әдәби әсәрләре. XIX–XX гасырларда туган телдәге (татар) әдәбият классиклары әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр). Туган телдәге (татар) балалар әдәбияты классиклары әсәрләре (шигырьләр, хикәяләр, әкиятләр). Төрле халыклар (Россиянең күпмилләтле дәүләт булуын исәпкә алып) әдәбияты үрнәкләре (хикәяләр, әкиятләр). Балалар өчен вакытлы матбугат басмалары (журналлар).

**Әдәби пропедевтика**. Төрле типтагы рифмалар, халык иҗаты һәм автор әдәбияты әсәрләренең жанр үзенчәлекләрен тану, әдәби әсәрләрдәге тел-сурәтләү чаралары (синонимнар, антонимнар, сынландыру, чагыштырулар, эпитетлар, метафоралар һ.б.) белән танышу һәм аларның кулланылу үзенчәлеген аңлау.

Укучыларның татар халык иҗатының кече жанрлары турындагы белемнәрен системалаштыру һәм «халык авыз иҗаты» төшенчәсен үзләштерү. Әдәби күзаллау алымнарын формалаштыру. Фольклор әсәрләре турында билгеле бер караш булдыру. Фольклор әсәрләренең жанр төрлелеген (хайваннар турында әкиятләр, тылсымлы һәм көнкүреш әкиятләре; кече фольклор формалары: табышмаклар, санамышлар, бишек җырлары, мәкальләр һ. б.) ачу.

Автор әдәбияты: хикәя, әдәби әкият жанры, шигырьләр. Шигырьнең үзенчәлекләре (ритм, рифма). «Тема» һәм «төп фикер» төшенчәләре. Төрле жанрдагы әсәрләрне практик тану («жанр» төшенчәсен үзләштермичә). Әсәрнең герое, хикәяләүче һәм автор турында күзаллау тудыру.

Текстның халык авыз иҗаты яки автор әсәре булуын билгеләү. Текстның жанр үзенчәлекләре (әкият, хикәя, шигырь, мәкаль, табышмак һ.б.). Әдәби һәм фәнни-популяр текстлар арасындагы аерманы, проза һәм шигырь текстларының аерымлыкларын күрсәтү. Әдәби әсәрдә автор позициясен табу (укытучы ярдәмендә), шулай ук геройның (лирик геройның) кичерешләрен аңлау.

**Укучыларның иҗади эшчәнлеге.** Әдәби әсәрне (яки аның аерым өлешләрен) рольләргә бүлеп уку. Шигырь һәм проза әсәрләрен сәнгатьле укый белү. Интонация, уку темпын аңлы рәвеш-

тә сайлый һәм текст үзенчәлекләре нигезендә кирәкле паузалар ясый алу. Дәреслектәге иллюстрацияләрне анализлый белү, аларны әдәби текстлар белән чагыштыру. Кече фольклор жанрларын практик үзләштерү (табышмаклар, санамышлар, эндәшләр), үз текстын иҗат итү һәм аны тәэсирле чаралар (мимикалар, ишарәләр, интонацияләр) ярдәмендә инсценировкалау. Телдән һәм язма рәвештә (аерым җөмләләр һәм зур булмаган сочинениеләр рәвешендә) үзеңнең шәхси күзәтүләрең һәм тәэсирләрең белән уртаклаша алу.

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү нәтиҗәләре башлангыч гомуми белем бирүнең Федераль дәүләт белем бирү стандартында формалаштырылган төп белем бирү программасын үзләштерү буенча «Туган тел һәм туган телдә әдәби уку» предмет өлкәсе нәтиҗәләренә карата куелган таләпләргә туры килә.

## ПЛАНЛАШТЫРЫЛГАН НӘТИҖӘЛӘР

### Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү укучыларда тәрбия эшчәнлегенең төп юнәлешләре буенча тәкъдим ителгән түбәндәге шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр формалаштырачак:

***патриотик һәм гражданлык тәрбиясе:***

- үз Ватаныңа — Россиягә югары кыйммәт итеп карау, шул исәптән илнең тарихын һәм мәдәниятен чагылдырган сәнгать әсәрләрен өйрәнү аша да;
- үзеңнең этномәдәни тәңгәллегеңне һәм Россия гражданины булуыңны аңлау;
- үз илеңнең һәм туган ягыңның үткәне, бүгенгесе һәм киләчәге белән бәйләнеш тою, шул исәптән сәнгать әсәрләрен өйрәнү барышында фикер алышу аша да;
- үз халкыңа һәм башка халыкларга хөрмәт белән карау, шул исәптән әдәби әсәрләр һәм фольклор әсәрләре аша да шундый ук хөрмәт тәрбияләүгә ирешү;

- әдәби әсәрләр һәм фольклор әсәрләрендә урын алган кыйммәтләргә, әдәп-әхлак нормаларына таянып, һәм гомумән, җәмгыятьнең бер әгъзасы булган кеше, аның хокуклары һәм бурычлары, хөрмәткә лаек булуы һәм абруе, кешеләр арасындагы үзара мөнәсәбәтләр турында беренчел күзаллау туу;

***рухи-әхлакый тәрбия:***

- уку нәтиҗәсендә һәм шәхси тормыш тәҗрибәсенә таянып, һәр кешенең индивидуаль шәхес булуын тану;
- тел нормалары, сөйләм әдәбе чикләрендә кешенең хәленә керү, хөрмәт һәм шәфкатьлелек күрсәтү, үз халәтен һәм хисләрен белдерү; башка кешеләрнең тойгыларын аңлау һәм уртаклашу, теләктәшлек күрсәтү;
- яшьтәшләре белән хезмәттәшлек итү, конфликтлар булдырмау һәм бәхәсле хәлләрдән чыгу юлларын табу, шул исәптән әдәби әсәрләр үрнәкләренә таяну;

***зәвык тәрбияләү:***

- мәдәниятебезне хөрмәт итү һәм аның белән кызыксыну, сәнгать төрләренә, үзеңнең һәм башка халыкларның традицияләренә, иҗатына ихтирам белән карау;
- сәнгатьнең төрле юнәлешләрендә, шул исәптән сүз сәнгатендә үз-үзеңне күрсәтергә, танытырга омтылу;
- физик тәрбия, сәламәт яшәү культурасы һәм эмоциональ тотрыклылык формалашу;
- әйләнә-тирә мохиттә өстәмә мәгълүмат эзләгәндә (шул исәптән цифрлаштырылган информацион кырда да), үзеңә һәм башкаларга мөнәсәбәттә сәламәт һәм имин яшәү кагыйдәләрен үтәү;
- үз фикереңне җиткерүнең кулай ысулларын сайлау, сөйләм этикеты нормаларын һәм аралашу кагыйдәләрен үтәү нигезендә физик һәм психик сәламәтлеккә зарар китермәү;

***хезмәт тәрбиясе:***

- кеше һәм җәмгыять тормышында хезмәтнең югары кыйммәт булуын (шул исәптән әдәби әсәрләрдән алынган мисаллар ярдәмендә дә) аңлау, хезмәт нәтиҗәсенә җаваплы

караш һәм сакчыл мөнәсәбәт, эшчәнлекнең төрле төрләрендә катнашу күнекмәләре, әдәби әсәрләр турында фикер алышу барышында танышкан төрле һөнәрләр белән кызыксыну;

***экологик тәрбия:***

- текстлар белән эшләү барышында табигатькә сакчыл мөнәсәбәт формалаштыру;
- үзенә зарар китерә торган гамәлләрне кабул итмәү;

***фәнни танып белү кыйммәтләре:***

- дөньяның фәнгә нигезләнгән картинасы турында беренчел күзаллаулар барлыкка килү, шул исәптән кайбер әдәби төшенчәләрне үзләштерү барышында да;
- танып белү мәнфәгатьләре, танып белүдә активлык, инициативалылык, кызыксыну һәм мөстәкыйльлек, шул исәптән әдәби әсәрләрне укуга игътибарлы мөнәсәбәт, уку даирәсен киңәйтүдә активлык һәм мөстәкыйльлек.

**Метапредмет нәтиҗәләр**

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын өйрәнү нәтиҗәсендә, укучыларда түбәндәге танып белү универсаль уку гамәлләре формалашачак.

***Төп логик гамәлләр:***

- төрле текстларны чагыштыру өчен, нигезләр табу, текстларның охшашлыгын күрсәтү;
- аерым бер билге буенча объектларны (текстларны) берләштерү;
- мәкальләрне, әйтемнәрне, фразеологизмнарны классификацияләү өчен төп үзенчәлекне билгеләү;
- укытучы тәкъдим иткән күзәтү алгоритмы нигезендә текстларда закончалыклар һәм каршылыклар табу; текстны тикшергәндә кулланылган гамәлләрнең алгоритмын анализлау, әлеге гамәлләрне мөстәкыйль рәвештә аерып күрсәтү;
- тәкъдим ителгән алгоритм нигезендә өйрәнү һәм гамәли бурычны хәл итү өчен, мәгълүматның җитмәвен ачыклау, җитешмәгән өстәмә мәгълүматны эзләргә өйрәнү;
- текстны анализлаганда, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗәләр ясау.

***Төп тикшеренү гамәлләре:***

- укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, сөйләм ситуациясе нигезендә үз фикереңне җиткерүне планлаштыру;
- биремне үтәүнең берничә вариантын чагыштыру, тәкъдим ителгән критерийлар нигезендә аеруча туры килә торганын сайлау;
- бирелгән план нигезендә катлаулы булмаган кечкенә тикшеренү үткәрү, проект биремен үтәү;
- нәтиҗәләрне формалаштыру һәм аларны текстка ясалган мәгънәви анализ нәтиҗәләре белән дәлилләп ныгыту; тәкъдим ителгән текстны анализлау барышында укытучы ярдәмендә сораулар формалаштыру;
- вакыйгалар, хәлләрнең мөмкин булган үсешен һәм бердәй яки охшаш шартларда аның нәтиҗәләрен фаразлау.

***Мәгълүмат белән эш:***

- мәгълүмат алу, төгәллек кертү чыганагын сайлау: кирәкле сүзлек, белешмәлек һ.б;
- бирелгән эш тәртибеннән чыгып, тәкъдим ителгән чыганактан (сүзлекләрдән, белешмәлекләрдән) төгәл мәгълүматны табу;
- мөстәкыйль рәвештә яисә укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы һәм төгәл булмаган мәгълүматны (сүзлекләргә, белешмәлекләргә, дәреслеккә мөрәҗәгать итеп) танып белү;
- Интернетта мәгълүмат эзләгәндә, өлкәннәр (педагогик хезмәткәрләр, ата-аналар яки аларны алмаштыручы законлы вәкилләр) киңәшен тотып, мәгълүмати иминлек кагыйдәләрен үтәү;
- уку бурычы таләбеннән чыгып, текст, график, видео, аудиоязма хәлендәге мәгълүмат булдыру һәм анализлау;
- таблица, схема рәвешендә китерелгән мәгълүматны аңлау; текстлар белән эшләүнең нәтиҗәләрен күрсәтү өчен, схемалар, таблицалар төзү.

Башлангыч мәктәп курсын тәмамлаганда, укучыда коммуникатив универсаль уку гамәлләре формалаша.

***Аралашу:***

- таныш мохиттә аралашу максатларыннан һәм шартларыннан чыгып, әйтелгән фикерләрне кабул итү һәм үз фикерләрен формалаштыру, хис-кичерешләрне белдерү;
- әңгәмәдәшкә хөрмәт саклау, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү;
- карашлар төрле булу мөмкинлеген тану;
- үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү;
- сөйләмне куелган бурычка нигезләнеп төзү;
- сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар (тасвирлама, фикер йөртү, хикәяләү) булдыру;
- парлап һәм төркемдә эшләү, кечкенә тикшеренү, проект биреме нәтиҗәләре турында кыскача чыгышлар әзерләү;
- чыгыш текстына күргәзмә материал (рәсемнәр, фоторәсемнәр, плакатлар) сайлау.

***Күмәк эшчәнлек:***

- типик шартларда күмәк бурычны үтәү өчен, укытучы тәкъдим иткән планга сыешырлык итеп, үзең өчен кыска һәм дәвамлы вакыт аралыгына максатлар, аңа ирешү алымнарын һәм вакытын билгеләү;
- уртак эшчәнлекнең максатын аңлау, аңа ирешү өчен, күмәк гамәлләр кылу: килешенеп вазифаларны бүлү, уртак эш барышы һәм нәтиҗәсе турында фикер алышу;
- җитәкчелек итү, йөкләмәләр башкару; буйсынырга, каршылыкларны мөстәкыйль рәвештә хәл итәргә әзерләү;
- үз өлешеңә тигән эшне башкаруда җаваплылык хисе булдыру;
- гомуми нәтиҗәдә үзең керткән өлешне бәяләү;
- тәкъдим ителгән үрнәкләргә таянып, күмәк проект биремнәрен үтәү.

Башлангыч мәктәп программасын тәмамлаганда, белем алучының түбәндәге **регулятив-универсаль уку гамәлләре** формалаша.

***Оештыру:***

- нәтиҗәгә ирешү өчен, уку бурычын хәл итү эзлеклелеген планлаштыру;
- сайлап алынган гамәлләрнең эзлеклелеген булдыру.

***Үз-үзеңне тикшерү:***

- уку эшчәнлегенең уңышы һәм уңышсызлыгы сәбәпләрен билгеләү;
- сөйләм хаталарын һәм текстларны анализлауга бәйле хаталарны булдырмау өчен, үзеңнең уку эшчәнлегеңә төзәтмәләр кертү;
- эшчәнлек нәтиҗәсен текстларны анализлауга куелган уку бурычы белән чагыштыру;
- текстлар белән эшләгәндә җибәрелгән хатаны табу;
- үз эшчәнлеге һәм сыйныфташлары эшчәнлеге нәтиҗәләрен чагыштыру, аларны тәкъдим ителгән критерийлар нигезендә объектив бәяләү.

**Предмет нәтиҗәләр**

«Туган телдә (татар телендә) әдәби уку» предметын дүрт ел дәвамында өйрәнү түбәндәге нәтиҗәләрне тәэмин итәргә тиеш:

- татар әдәбиятын дөньякүләм һәм милли мәдәният күренеше, тормышны танып белүнең махсус ысулы, халкыбызның милли-мәдәни байлыгы, әхлакый кыйммәтләрне һәм традицияләрне саклау һәм тапшыру чарасы буларак аңлау;
- татар әдәбияты әсәрләрен өйрәнү нигезендә татар теленең коммуникатив-эстетик мөмкинлекләрен аңлау;
- туган телдәге әдәбиятны укуның шәхси үсеш, үзеңне, дөньяны, милли тарихны һәм мәдәниятне танып белү; мәдәни тәңгәллегеңне тану; татар әдәбиятын системалы укуга ихтыяҗ булдыру өчен, аның мөһимлегенә төшенү;
- укылган әсәрдәге каһарманнар гамәлләренең әхлакый нормалар белән тәңгәллеген ачыклау, әлеге гамәлләрне әхлакый бәяләүне нигезләү;
- метафораларның, сынландыруларның, эпитетларның милли үзенчәлеген аңлау;
- уку күнекмәләрен камилләштерү (кычкырып һәм эчтән уку, интерпретациянең элементар алымнарын белү, әдәби, фәнни-популяр текстларны анализлау һәм үзгәртеп кору);

- татар әдәбияты әсәрләрен уку тәҗрибәсен мөстәкыйль куллану (тыңланган / укылган текст буенча фикер алышуда катнашу, текстка сылтамалар белән үз фикереңне исбатлау һәм раслау; текст үзенчәлеген саклап, тыңлаган яки укыган текстның эчтәлеген кыскача яки тулысынча сөйләү; укылган әсәрләр нигезендә коммуникатив бурычны (төрле адресат өчен) исәпкә алып, телдән хикәя төзү, шигъри әсәрләрне яттан уку);
- кызыксындырган әдәбиятны мөстәкыйль сайлау һәм кызыксыну чикләрен киңәйтә бару;
- өстәмә мәгълүмат алу өчен, белешмә чыганаклардан файдалану.

**Уку елы тәмамланганда, 3 нче сыйныф укучысы:**

*База өлешендә:*

- кычкырып укырга (хәрефләрне һәм иҗекләрне төшереп калдырмыйча, урынын алыштырмыйча, орфоэпик интонация нормаларын истә тотып, иҗекләп түгел, сүзләр белән дөрес уку техникасына ия булырга);
- уку мәсьәләсенә туры китереп укуның төрләренә (өйрәнү, сайлап уку, танышу) мөрәҗәгать итәргә;
- укылган әсәрләргә карата (шул исәптән проблемалы характердагы) сораулар бирергә, укылган текст буенча әңгәмәдә катнашырга;
- укытучы ярдәме белән автор позициясен билгеләргә;
- татар әдәби теленең нормаларын саклап, телдән диалогик һәм монологик сөйләм төзергә;
- текстның планын төзергә (сорауларга нигезләнеп, номинатив), әсәрнең эчтәлеген (җентекләп, сайлап, кыскартып) сөйләргә;
- төрле авторларның 3–4 шигырен яттан сөйләргә;
- контекстка таянып, шулай ук сүзлекләр һәм башка мәгълүмат чараларын кулланып, таныш булмаган сүзнең мәгънәсен аңлатырга;
- матур әдәбият һәм төрле жанрдагы фольклор әсәрләренә мисаллар китерергә;

- халык авыз иҗаты әсәрләрендә һәм матур әдәбиятта сурәтләү чараларын (сынландыру) табарга һәм аерырга;
- укылган әсәрнең дәвамын уйларга.

*Предметны тирәнтен өйрәнү өлешендә:*

- кычкырып укырга (хәрефләрне һәм иҗекләрне төшереп калдырмыйча, урынын алыштырмыйча, орфоэпик интонация нормаларын истә тотып, иҗекләп түгел, сүзләр белән дөрес уку техникасына ия булырга);
- уку мәсьәләсенә туры китереп укуның төрләренә (өйрәнү, сайлап уку, танышу) мөрәҗәгать итәргә;
- укылган әсәрләргә карата (шул исәптән проблемалы характердагы) сораулар бирергә, укылган текст буенча әңгәмәдә катнашырга;
- укытучы ярдәме белән автор позициясен билгеләргә;
- татар әдәби теле нормаларын саклап, телдән диалогик һәм монологик сөйләм төзергә;
- язучы һәм шагыйрьләрне – өйрәнелә торган әсәрләр авторларының исемнәрен атарга; алар язган әсәрләрнең исемнәрен әйтергә һәм укылган текстларның эчтәлеген сөйләргә;
- текстның планын төзергә (сорауларга нигезләнеп, номинатив), әсәрнең эчтәлеген (җентекләп, сайлап, кыскартып) сөйләргә;
- төрле авторларның 4–5 шигырен яттан сөйләргә;
- укылган әдәби әсәрләрне башка сәнгать төрләре белән чагыштырырга;
- халык авыз иҗаты әсәрләрендә һәм матур әдәбиятта сурәтләү чараларын (чагыштыру, эпитет) табарга һәм аерырга;
- әдәби текстны шәрехләргә, күргән, укылган һәм тыңланган турында фикер һәм хисләрне белдерергә;
- укылган әсәргә охшатып әсәрләр иҗат итү нигезендә әсәр язарга;
- текст-фикерләмә язарга өйрәнә.

# ТЕМАТИК ПЛАНЛАШТЫРУ

| Тема | Эчтәлек | Укучылар эшчәнлегенең төрләре |
|---|---|---|
| Китап – белем чишмәсе<br>(6 сәгать) | Китапның кыйммәтен, китап укуның кеше тормышындагы урынын, кешенең шәхес буларак формалашуын чагылдырган әсәрләр:<br>**Җ. Тәрҗеманов.** «Якын дус» (*яттан өйрәнү өчен*);<br>**М. Гафури.** «Китап һәм балалар»;<br>**Г. Бәширов.** «Китап җене кагылган малай»;<br>**В. Нуриев.** «Китап»;<br>**З. Туфайлова.** «Безнең китапханәдә»;<br>**Х. Халиков.** «Китап докторы».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Х. Шабанов.** «Кадерлә син китапны». | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып һәм эчтән уку.<br>Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү.<br>Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә укылган әсәрнең темасын һәм төп фикерен билгеләү, текстка карата сораулар, шулай ук проблемалы сораулар төзү, әсәр геройларын, аларның эш-гамәлләрен бәяләү,<br>геройларның хисләрен белдерүче тел-сурәтләү чараларын табу, билгеләү,<br>тексттан әдәби тел-сурәтләү чараларын табу һәм мәгънәсен аңлау, аларның әһәмиятен билгеләү.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |

| | | |
|---|---|---|
| Халык авыз иҗаты.<br>Әкиятләр<br>(5 сәгать) | Халык иҗаты әсәрләре: әкиятләр. Әкиятләрнең төрләре, әкият персонажлары. Яхшылыкның һәрвакыт явызлыктан өстенлеге.<br>Татар халык әкиятләре:<br>«Гөлчәчәк»;<br>«Шүрәле»;<br>Рус халык әкияте «Казлар-аккошлар».<br>Нугай халык әкияте «Карт һәм су анасы».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>Татар халык әкиятләре:<br>«Бүре, кәҗә һәм кәбестә».<br>«Ике ялкау». | Тыңлау: сөйләмне тыңлап кабул итү, сүзнең яңгырашын һәм мәгънәсен бердәй кабул итү.<br>Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү, җавапларны текстттан мисаллар китереп дәлилләү.<br>Фольклор әсәрләренең текстлары белән эшләү: текст эчтәлегендәге төп, әһәмиятле якны табу, образлар системасын билгеләү.<br>Текст персонажларының портретын табу, геройларның холкы һәм аларның эш-гамәлләре арасындагы бәйләнешләрне билгеләү.<br>Тестның эчтәлеген тәфсилләп сөйләү.<br>Фольклор жанрларының аерымлыкларын табу.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку.<br>Проект эше эшләү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |

| | | |
|---|---|---|
| Әкиятләр илендә<br>(5 сәгать) | Автор әкиятләре һәм аларның халык әкиятләреннән аермасы.<br>Автор әкиятләре:<br>**Г. Тукай.** «Су анасы» *(яттан өйрәнү өчен)*;<br>**А. Алиш.** «Сертотмас үрдәк»;<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**И. Дәүләтшин.** «Алпамыш шәһәргә килде».<br>**Р. Миңнуллин.** «Туп тибәргә яратучы малай турында кечкенәкият». | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып һәм эчтән уку.<br>Уку диалогы: укылган текстка караган сорауларга телдән җавап бирү, җавапларны тексттан мисаллар китереп дәлилләү, текст буенча сораулар әзерләү.<br>Әдәби текст белән эш: мөстәкыйль рәвештә әсәрнең төп фикерен һәм темасын, вакыйгаларның эзлеклелеген билгеләү, аның буенча план төзү, әкият геройларын чагыштыру.<br>Текстның аерым (сайлап алынган) өлешләрен сөйләү.<br>Иҗади эш: әкият сюжетын дәвам итү, аны тәмамлап кую, охшаш сюжетлы әкият иҗат итү. |

| | | |
|---|---|---|
| Безнең нәни дусларыбыз (7 сәгать) | Кеше һәм табигать арасындагы мөнәсәбәтләрне, кошлар һәм җәнлекләр образларын чагылдырган әсәрләр:<br>«Кем нәрсә ярата» әкияте;<br>**Й. Миңнуллина.** «Этем югалды бүген»;<br>**Р. Миңнуллин.** «Акбайга»;<br>**Н. Каштанов.** «Йөнтәс песи»;<br>**А. Бикчәнтәева.** «Сөйкемсез песи»;<br>**М. Җәлил.** «Карак песи» *(яттан өйрәнү өчен)*;<br>**Л. Әмирханова.** «Минем нәни дусларым»;<br>**Ф. Садриев.** «Сары чәчкәләр».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Н. Гыйматдинова.** «Сертотмас кәҗә».<br>**Л. Лерон.** «Хыялый Акбай» | Кычкырып уку: текстны сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби әсәрне интерпретацияләү: рольләргә бүлеп уку.<br>Уку диалогы: әсәрнең исеменә, рәсемнәр һәм ачкыч сүзләргә нигезләнеп, эчтәлеген фаразлау; укылган текстның эчтәлеге буенча, телдән һәм язма рәвештә, сорауларга җавап бирү, җавапларны тексттан мисаллар китереп дәлилләү.<br>Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларын, аларның эш-гамәлләрен бәяләү.<br>Телдән монолог һәм кара-каршы әңгәмә (диалог) төзү.<br>Сөйләү: фикерләү элементлары булган хикәяләүгә корылган текст төзү.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Проект эше эшләү. |

| | | |
|---|---|---|
| Изге сүз<br>(5 сәгать) | Әхлакый кыйммәтләрне ачып бирә торган әсәрләр:<br>**М. Галләмова.** «Дуслар»;<br>**Д. Гайнетдинова.** «Изге сүз»;<br>**И. Туктар.** «Рәхмәт һәркемгә рәхәт»;<br>**Х. Халиков.** «Якты сүз»;<br>**Р. Гыйззәтуллин.** «Кеше әйбере»;<br>**Р. Фәйзуллин.** «Ничек яхшы булырга?» (*яттан өйрәнү өчен*)<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**А. Алиш.** «Утлы йомырка».<br>**А. Әхмәт.** «Минеке, тимә!»: | Текстның эчтәлеген аңлау максаты белән кычкырып һәм эчтән уку.<br>Уку диалогы: укылган текст эчтәлегенә караган сорауларга җавап бирү, текстка карата сораулар, шулай ук проблемалы сораулар да төзү.<br>Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларын, аларның эш-гамәлләрен бәяләү. Автор позициясен билгеләү, тел-сурәтләү чараларын тексттан табу, геройның хис-кичерешләрен белдерүдә аларның ролен һәм мәгънәсен аңлау, әһәмиятен билгеләү.<br>План буенча текстның эчтәлеген сөйләү.<br>Әсәрнең укылган аерым өлешләре, кисәкләре нигезендә сүз белән сурәт ясау.<br>Иҗади эш: әсәрне (аерым бер өлешен) сәхнәләштерү (инсценировка эшләү), фикерләү элементлары белән текст булдыру.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу. |

| | | |
|---|---|---|
| Сәламәт яшибез, спорт белән шөгыльләнәбез<br>(6 сәгать) | Сәламәт яшәү рәвеше, физкультура һәм спорт турындагы әсәрләр:<br>**Х. Халиков.** «Хәрәкәттә – бәрәкәт»;<br>**Җ. Дәрзаман.** «Бар да җитез»;<br>**Р. Миңнуллин.** «Күңелле тәнәфес»;<br>**Ш. Галиев.** «Витаминлы хәрефләр»;<br>**В. Монасыйпов.** «Шифалы табиблар»;<br>**С. Әхмәтҗанова.** «Үрнәк алыйк» (*яттан өйрәнү өчен*);<br>**Г. Гыйльманов.** «Универсиада»;<br>**Й. Шәрәпова.** «Татарстан – спорт иле».<br>*Сыйныфтан тыш уку:*<br>**Ф. Яруллин.** «Озын куллы кыз». | Кычкырып уку: текстны сәнгатьле итеп уку.<br>Әдәби текст белән эш: укылган әсәрнең төп фикерен билгеләү, әсәр геройларына бәя бирү, геройның хис-кичерешләрен белдерә торган тел-сурәтләү чараларын күрсәтү.<br>Әдәби тел нормаларын саклап, телдән монологик һәм кара-каршы әңгәмә (диалогик) сөйләм төзү.<br>Декламацияләү: шигырьне сәнгатьле итеп яттан сөйләү.<br>Тикшерү эше: тест биремнәрен үтәү.<br>Сыйныфтан тыш уку: уку өчен тәкъдим ителгән исемлектән китап сайлап алу, билгеле бер темага караган әсәрне сайлап алу һәм аны сыйныфта укылган әсәрләр белән чагыштыру.<br>Иҗади эш: китап турында хикәя төзү. |

## ДӘРЕСЛЕК БЕЛӘН ЭШЛӘҮ ТӘРТИБЕ

Дәреслектәге һәр тема өйрәнелә торган әсәр белән бәйләп бирелә. Алдагы сыйныфлар өчен эшләнгән дәреслекләрдәге кебек үк теманы өйрәнүнең башыннан ахырына кадәр таныш персонаж-геройлар – Алмаз, Гөлназ, Нур, Дәреслек белемнәрне укучылар белән бергә үзләштерә. 3 нче сыйныф дәреслегендә аларга татар халык әкияте герое Гөлчәчәк тә кушыла.

Әлеге персонажлар укучылар белән өйрәнелә торган темага һәм куелган уку мәсьәләсенә бәйле сөйләшү алып баралар. Мондый әңгәмәләр традицион рәвештә теманың башында һәм ахырында бирелә. Билгеле, алар һәм төрле коммуникатив юнәлешле биремнәр укучыларның телдән һәм язма сөйләмнәрен үстерүгә хезмәт итеп кенә калмыйлар, балаларның күңелләрен үстереп, әдәби әсәрне өйрәнүгә мотивлаштыралар да.

Дәреслек ике төрле мәктәпне (татар һәм рус), ягъни ике дәрәҗәдә укуны (предметның база өлешен өйрәнүчеләр һәм тирәнтен өйрәнүчеләрне), димәк, бер-берсеннән бик нык аерылып торган укучыларга белем бирүне күздә тота.

3 нче сыйныф дәреслегендә дә төрле дәрәҗәдә өйрәнелә торган материаллар аерып бирелә. Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр өчен алар өстәмә рәвештә дәреслекнең читләре буйлап төс һәм график сурәт (яшел пунктирлар) ярдәмендә билгеләнә. Ике дәрәҗәгә аерып бирү әсәр ахырыннан соң бирелгән сорау-биремнәрдә дә чагылыш таба. Укытучы өчен методик әсбапта предметны тирәнтен өйрәнү буенча киңәшләр, аерым темалар зәңгәр төс белән билгеләнә.

Дәреслектәге биремнәр, аеруча база өлешендәгеләре, теманы өйрәнүдә әллә ни авырлык тудырмаска тиеш. Тирәнтен өйрәнүчеләр өчен булган өстәмә материаллар, сорау-биремнәр укучыларның иҗади мөмкинлекләрен, билгеле бер әдәби-теоретик төшенчәләрне аңлауны күздә тотып төзелде.

Телне төрле дәрәҗәдә белгән укучыларга әдәби текстны кабул итү һәм аңлауны берникадәр җиңеләйтү өчен, укучыларга сүзлекчә тәкъдим ителә. Биредә текстта очраган таныш булмаган

сүз, аның татар телендәге синонимы (синоним булмаган очракта урыны буш калдырылган) һәм рус теленә тәрҗемәсе бирелә.

Дәреслектә үзләштерү өчен әдәби-теоретик төшенчәләр дә тәкъдим ителә. Аларның саны күп түгел. Шулай ук 3 нче сыйныфта ятлау өчен елга 3–4 әсәр бирелә. Предметны тирәнтен өйрәнү өлешендә аларның саны 4–5.

Үткән материалны төрле формада кабатлау күздә тотыла. 3 нче сыйныф дәреслегендә теманы гомумләштерергә ярдәм иткән сорау-биремнәр, дидактик характердагы төрле әдәби уеннар тәкъдим ителә.

Сабантуй бүләге рәвешендә бирелгән мәкаль-әйтемнәр белемнәрне ныгыту яки дәрескә йомгак ясау этабында уңышлы кулланыла ала.

Дәреслеккә шулай ук дәрестән тыш уку өчен кайбер әсәрләр дә кертелгән.

«Әдәби уку» һәм «Туган тел (татар теле)» дәреслекләре берберсен тулыландырып баралар. Бу эш темаларда да, формалаштыра торган компетенцияләрдә дә чагылыш таба. Балалар ияләшеп өлгергән персонажлар ике дәреслектә дә очрый.

Дәреслекнең электрон вариантында төп материал белән беррәттән һәр дәрестә куллану өчен өстәмә заманча материаллар урын алды: рәсемнәр, интерактив форматтагы эш төрләре, биремнәр һ.б. Алар балаларның кызыксыну даирәләрен, яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып эшләнде. Шулай ук биредә аерым текстларның аудиоязмалары бирелә. Текст белән эшләгәндә аларны тыңлатып була.

Дәреслектәге уку материалы видеодәресләр форматында да тәкъдим ителә. 3 нче сыйныф өчен барлыгы 12 тема буенча күләме ягыннан зур булмаган видеороликлар булдырылды. Аларның эчтәлеге Федераль дәүләт белем бирү стандартлары таләпләренә туры килә һәм алар Федераль эш программалары нигезендә эшләнгән. Видеодәресләрнең төп максаты – укучыларны яңа материал белән таныштыру, аны презентация яки анимация чаралары ярдәмендә аңлату. Видеодәресләр Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтында урнаштырылган.

# ДӘРЕС ЭШКӘРТМӘЛӘРЕНЕҢ ҮРНӘКЛӘРЕ

Методик ярдәмлектә бирелгән дәрес үрнәкләре укытучыга бары юнәлеш бирү һәм бу дәрестә игътибардан читтә калмаска тиешле төп моментларны искәртүне генә максат итә.

Сыйныфтагы укучыларның гомуми мөмкинлеген һәм һәр укучының аерым мөмкинлекләрен бары укытучы үзе генә белә. Шуңа күрә бирелгән дәресләр үрнәгендә генә эш итү мөмкин түгел. Билгеле бер әсәрне уку, сүзлек белән эшләү, сорауларга җавап бирү, әңгәмәнең ни рәвешле үткәрелүе укытучыдан тора. Әлбәттә, ул бу эш алымнарын үзенчә куллана ала. Телне яхшы белмәгән балалар өчен текст белән эш дөрес уку һәм укыганны аңлау, гади сорауларга җавап бирү белән чикләнергә мөмкин. Өстәмә сорау-биремнәр, үзе сайлаган темага әңгәмә оештыру – укытучы иркендә. Шуңа дәрес үрнәкләрендә бу өлешкә киң тукталмадык.

**Тема**: Иң якын дустым

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – китап кешенең дусты була алуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Җәвад Тәрҗемановның «Якын дус» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дәрес укучылардан җәйге ялны ничек үткәрүләрен сорашудан башланып китә. Бу вакытта Хөрмәтле Дәреслек, Алмаз, Гөлназ һәм Нурның китапта бирелгән әңгәмәсен кулланабыз. Шулай ук иллюстрацияләргә игътибар итү кирәк. Дәреслек персонажлары үзләре ялларын ничек үткәрүләре турында сөйлиләр һәм укучылардан да сорашалар. Бередә Нурның, җәй көне укып, хәзер укучыларга тәкъдим иткән китапларына аерым игътибар бирү сорала. Шул рәвешле, укучылар өйрәнеләчәк темага килеп чыгалар.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Нәкый Исәнбәтнең дәреслектә бирелгән шигырен уку дәреснең темасын һәм максатын фаразларга мөмкинлек бирә.

«Китап кешенең дусты була аламы?» дигән сорау аша шигырьне өйрәнүгә кереп китү отышлы булачак.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрестә Җәвад Тәрҗемановның «Якын дус» исемле шигырен уку каралган. Бу очракта видеодәрес материалын да куллanyrга мөмкин. Алга таба шигырьне берничә яхшы укучыдан укытырга була.

Сорауларга җавап бирү барышында шигырьне ике өлешкә бүлү укучыларда билгеле бер авырлык тудырырга мөмкин. Бу очракта «Беренче дүрт юлда нәрсә турында сүз баруы турында белеп буламы?» дигән сорау аша укучыларны фаразлатабыз. Икенче дүрт юлны укыгач, укучылар сүзнең нәрсә турында баруын ачыклап булмавын билгелиләр. Бары тик өченче дүртьюллыкта гына аның китап икәнлеген ачыклый алачаклар. Тирәнтен өйрәнүчеләргә

дәреслектә өстәмә рәвештә уйлануга этәрүне, үз фикерләрен әйттерүне күздә тоткан сорау-биремнәр тәкъдим ителә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Биредә дуслык турында сөйләшү-әңгәмә оештырып була. Тагын бер эш төре буларак, укучының дусты турында сөйләвен дә кулланырга мөмкин.

**VI. Өйгә эш бирү.**

Шигырьне ятлап килергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Китап укый балалар

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – китапка сакчыл караш булдыру.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, бәяләү; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Мәҗит Гафуриның «Китап һәм балалар» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Укучылардан Алмазның тема башында бирелгән табышмагына җавап таптырабыз.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү рәвешендә үткәрелә ала. Алдагы дәрестә шигырьне яттан сөйләргә бирелгән иде.

Дәреслектә (11 бит) Нурның китап турындагы акыллы сүзләрен укып та, сөйләшү үткәреп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар алдагы этапта эшләнгәннәр буенча бу дәрестә дә китап турында сүз барачагын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Мәҗит Гафуриның «Китап һәм балалар» шигыре укыла, сүзлек эше үткәрелә, сорауларга җавап алына.

Тирәнтен өйрәнүчеләргә, шигырьнең эчтәлегеннән чыгып, сүзнең кайсы заман турында, нинди җирдә баруын билгеләтү мөһим. Бер-ике җөмлә белән Мәҗит Гафуриның XX гасыр башында яшәгән әдип булуы турында мәгълүмат җиткерү дә файдалы булачак. Әлеге сорауларны, авырлык тудырмаса, база өлешен өйрәнүчеләргә дә тәкъдим итеп була.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәрестә, китапны уку кагыйдәләрен искә төшереп, шул турыда сөйләшү үткәрү күздә тотыла. Дәреслектә укучыларга таныш Мансур исемле малай турында хикәя бирелә. Укытучы хикәяне укый, шуннан соң аның буенча сөйләшү үткәрелә, Мансурның гамәлләрен бәяләргә тәкъдим ителә. Бу укучыларга үзләренә дә билгеле бер нәтиҗә ясау мөмкинлеге бирәчәк.

Вакыт калган очракта, база өлешен генә өйрәнүчеләргә дә әлеге хикәя белән танышырга тәкъдим итү укучыларга файдалы булачак.

**VI. Өй эше бирү.**

Мәҗит Гафуриның «Китап һәм балалар» шигырен сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә, Гомәр Бәшировның «Китап җене кагылган малай» хикәясен укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кадерле китап

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – китапның кадерен белү, бүләккә китап бирүнең дөрес гамәл булуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, үзбәя; мәгълүмат алу, укытучы тәкъдим ителгән чыганактан төгәл мәгълүматны табу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Вакыйф Нуриевның «Китап» хикәясенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

Китап турында мәкаль белән таныштыру укучыда темага кызыксыну уятырга мөмкин.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Укучылар Мәҗит Гафуриның «Китап һәм балалар» исемле шигырен сәнгатьле итеп укыйлар, тирәнтен өйрәнүчеләр Гомәр Бәшировның алдагы дәрестә өйрәнелгән «Китап җене кагылган малай» хикәясе буенча бирелгән өй эшен дә сөйлиләр.

«Кадерле китап» темасының башында бирелгән Хөрмәтле Дәреслек белән Нурның әңгәмәсен кулланабыз, китапның борынгы нөсхәләре, гарәп язулы китаплар турында сөйлибез. Бу вакытта гасырларны, даталарны кулланып эшләргә була. 200 ел элек дигәндә, кайчан, кайсы гасырда булуын санап чыгарырга кушу укучыда кызыксыну уятачак, предметара бәйләнеш булдырачак.

Сөйләшү вакытында очраган *әдип, нәшер итү* сүзләренә аңлатма биреп китү кирәк. Бу эш тирәнтен өйрәнүчеләр өчен алдагы теманың дәвамы рәвешен ала, база өлешен генә өйрәнүчеләр өчен яңа материал буларак кабул ителә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Вакыйф Нуриевның «Китап» исемле хикәясен уку һәм анализлау традицион рәвештә алып барыла: текст укыла, сүзлек эше башкарыла, сорауларга җавап бирелә. Дәреслектә бирелгән иллюстрацияләр буенча сөйләшү дә оештырабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Биредә хикәяне укучыларга чылбыр буенча укытырга мөмкин. Шулай ук (хикәядә сүз барган) Габдулла Тукайның «Шүрәле» китабы турында сораштыру оештырырга мөмкин. Әлеге эш база өлешен генә өйрәнүчеләр белән дәрестә вакыт калса гына үткәрелә.

Габдулла Тукайның «Шүрәле» китабының төрле нөсхәләреннән күргәзмә оештырып була. Ул электрон форматта да булырга мөмкин.

Гөлназның «Китап – яхшы бүләк» дигән мәкале укучыларны китапны бүләккә бирү турында фикерләшүгә алып чыга.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Безнең китапханә

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – китапханәнең әһәмиятен аңлау, анда үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, алгоритм нигезендә эшләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилле җиткерә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Зәкия Туфайлованың «Безнең китапханә» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен). / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

Дәресне Шәүкәт Галиевнең «Хәзинә» исемле шигырен укудан башлап җибәрергә мөмкин.

**Хәзинә**

Хәзинәләрне
Борын-борыннан
Эзләп бакканнар
Төрле урыннан.
Мөгаен, син дә
Уйга каласың,
Хәзинә, диеп
Хыялланасың.

Ята кебектер
Таулар артында.
Ә үзе сиңа
Бик тә якында.
Төшә аласың
Бик тиз эзенә –
Китапханәдә
Ул бай хәзинә.

*Шәүкәт Галиев*

Укучыларга: «Мин дәрес башланганчы, шул хәзинәгә – мәктәп китапханәсенә кереп, сезгә кызыклы китаплар алып чыктым әле», – дия алабыз.

**II. Актуальләштерү.**

Китапханә турында сөйләшүгә алып кереп китәбез. Бу вакытта дәреслек персонажларының әңгәмәсен куллана алабыз.

Китапханә, аның функцияләре турында сөйлибез. Укучылардан китапханәләргә ничек йөрүләре турында сораштырабыз. Сөйләшү вакытында дәреслектәге иллюстрацияләрне дә кулланабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреснең төп өлешендә Зәкия Туфайлованың «Безнең китапханә» исемле шигырен өйрәнү каралган. Бу очракта видеодәрес

материалын кулланырга мөмкин. Әсәрне өйрәнү аны сәнгатьле итеп уку, беренчел тәэсирләрне уртаклашу, сүзлек эше, сорауларга җавап бирү рәвешендә оештырыла. Гөлназның бу эшкә нәтиҗәсен укытабыз, укучыдан аның фикере белән килешү-килешмәүләрен сораштырабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Тема белән бәйле рәвештә укучыларга китапханәдә үзеңне тоту кагыйдәләрен аңлату мөһим. Бу вакытта кагыйдәләр белән аларны санап китеп таныштырырга була. Алар дәреслектә бирелә. Шулай да мисал өстендә, аерым тормыш ситуациясендә аңлату отышлырак булыр. Дәреслектән Мансурның китапханәгә барып китап алу вакыйгасы турында укып, укучылар аның үз-үзен тотышын күзәтү, аны дөрес эшләгән һәм ялгышлык җибәргән эш-гамәлләрен күрсәтеп бәяләү аша, үзләре өчен нәтиҗә ясыйлар. Бу эш тирәнтен өйрәнүчеләр өчен тәкъдим ителә. Шул ук вакытта база өлешен генә өйрәнүчеләр өчен хикәяне (вакыт калганда) уку артык булмас.

**VI. Өй эше бирү.**

Китапханәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен табличка рәвешендә язып килергә кушарга мөмкин. Алда укылган хикәя ярдәмгә киләчәк.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Китаплар да авырый

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – китапка карата сакчыл булу, аны кадерләп тотуның әһәмиятенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә

бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Хәкимҗан Халиковның «Китап докторы» шигыренең эчтәлеген белү, төп фикерне билгеле алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Алдагы дәрестә өй эше итеп китапханәдә үз-үзеңне тоту кагыйдәләрен табличка рәвешендә язып килергә кушылган була. Шуларны барлыйбыз, укучылардан кабат укытабыз һәм кагыйдәләрдә бирелгән китап ертылган, төбе төшкән булса, аны ябыштырып «дәвалау» кирәклеккә игътибар иттереп, әһәмиятен билгеләп узабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын һәм максатын билгеләү өчен персонажларның 30 биттәге диалогы белән таныштырабыз. Шуларга нигезләнеп, укучылар дәрестә нәрсә турында сүз барачагын фаразлый алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Хәкимҗан Халиковның «Китап докторы» исемле шигыре укыла. Аны электрон дәреслектә бирелгән аудиоязмадан да тыңлатырга мөмкин. Аның буенча сорауларга җаваплар алына. Игътибарны рәсемгә юнәлттереп, сөйләм үстерү өстендә эш үткәрергә мөмкин. Китапны «дәвалау» өчен нинди кораллар кирәк булуын

барлыйбыз, алар белән эшләү тәртибен сораштыра алабыз. Бу вакытта персонажларның 30 биттә бирелгән диалогы ярдәмгә килә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Рус шагыйре Сергей Михалковның дәреслектәге «Китап» шигырен укытып, китапның кеше тормышындагы роле турында әңгәмә оештырырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кешене китап үстерә (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – китапның кеше тормышындагы, аның төрле яклап үсешендәге әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилле әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – белемнәрне гомумиләштереп системага сала белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү**.

Хөрмәтле Дәреслекнең 31 биттә бирелгән тәкъдиме белән танышу, шуның аша укучыларны дәрестә эшләргә кызыксындыру.

**III. Уку мәсьәләсен кую**.

Укучылар дәрестә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлаячакларын фаразлыйлар.

**IV. Белемнәрне ныгыту**.

Дәреслектә тәкъдим ителгән сорауларга җавап бирү. Бу вакытта «Китап – белем чишмәсе» темасы кысаларында өйрәнелгәннәр искә төшерелә, белемнәр ныгытыла. Ахырдан проблемалы сорау бирелеп, аңа җавапны фаразлап, сыйныф белән эшләү күздә тотыла. Шуңа дәлил рәвешендә Йолдызның «Куркыныч уй» дигән шаян шигыре укылып, аның буенча сөйләшү оештырыла.

Яраткан китабың турында сөйләргә тәкъдим итү соңгы бирем булырга мөмкин. Укучыга авыр булса, алдан сөйләргә әзерләнеп килү мөмкинлеге бирәбез. Шул китапны алып килергә дә кушып була.

**V. Өй эше бирү.**

Яраткан китабың турында сөйләргә яки китапка реклама ясарга әзерләнеп килергә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Борын-борын заманда...

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – яхшылык, явызлык төшенчәләренә төшенү, аларны бер-берсеннән аера белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; төрле текстларны чагыштыру өчен нигезләр табу, текстларның охшашлыгын билгеләү, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилле әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Гөлчәчәк» татар халык әкиятенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

«Борын-борын заманда яшәгән, ди, булган, ди...» Шундый сүзләр белән башланып китә әкиятләр, дип», – Хөрмәтле Дәреслекнең сүзләре белән таныштырабыз. Вакыйгаларның ни өчен борынгы заманда баруын ачыклыйбыз.

**II. Актуальләштерү.**

Дәреслектә урын алган Алмаз, Нур һәм Гөлназның диалогын укытабыз. Персонажларның сөйләшүенә кушылып китеп, укучыларның нинди әкиятләр укырга яратуларын ачыклыйбыз, бу турыда сөйләтәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар, алдагы этапта сөйләшкәннәргә нигезләнеп, бер авырлыксыз дәрестә әкиятләр турында сүз барачагын билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәреслек персонажлары сөйләгән әкиятләрне кем иҗат иткәнлеген искәртү кирәк. Нур халык әкиятләре турында мәгълүмат бирә, без укучыларны халык әкиятенә бирелгән билгеләмә белән таныштырабыз.

Әлеге дәрестә «Гөлчәчәк» татар халык әкиятенең беренче өлешен өйрәнү планлаштырылган. Әкиятнең башын укытучы үзе укый, укучыларның беренчел тәэсирләрен белешә. Укучылар укылган өлешкә, укытучы белән бергәләп, комментарийлар бирә. Алга таба әкиятне укучылар укый. Сүзлек эше башкарыла. *Юлдан яздыру* фразеологизмының мәгънәсен ачыклыйбыз.

Тексттан соң бирелгән сораулар әкият геройлары белән алга таба нәрсә буласын фаразлауны да исәпкә алып төзелгән.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр өчен бирелгән өстәмә сораулар укучыларның сөйләмен үстерүне, сүз белән эшләүне күздә тота. Авырлык тудырмаган очракта аларны рус мәктәбендәге татар төркемнәрендә укучыларга да тәкъдим итеп була.

Тема ахырында бирелгән диалог укучыларны киң күңеллелек, кешеләргә игелек кылу, яхшы булу турында сөйләшүгә алып чыга. Укучылардан бу турыдагы фикерләрен сораштыру тәрбияви максатны күздә тота.

Әлеге этапта укучыларның парлап эшләве рәвешендә китаплардан нинди кызыклы яки файдалы нәрсәләр хакында белүләре турында диалог төзетергә мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Мәкальләр белән эшләү отышлы булып санала. Аерым мәкальләрнең әкият текстына тәңгәллеге ачыклана.

**VI. Өй эше бирү.**

Әкиятнең өйрәнгән өлешен сәнгатьле итеп укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Бүген барып, кичә кайттым, мин дә булдым аларда

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – үз-үзеңә ышаныч, мәрхәмәтлелек, киң күңелелек төшенчәләрен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Гөлчәчәк» исемле татар халык әкиятенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү. Әкиятнең укылган өлешен сөйләтеп, Гөлчәчәк белән булган хәлләрне искә төшерәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Гөлназ, Нур һәм Алмазның 43 биттә бирелгән сөйләшүен укытабыз. «Сезнең дә Гөлчәчәк белән алга таба нәрсәләр булганын беләсегез киләдер», – дип укучыларда кызыксыну уятып, уку мәсьәләсен билгеләтәбез, алга таба әкиятнең дәвамын укуга мотивлаштырабыз.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әкиятнең дәреслектә бирелгән икенче өлеше укыла, сүзлек эше оештырыла. Тексттан соң бирелгән сораулар укучылар өчен

авыр булмаячак. Аларга текстның эчтәлегенә нигезләнеп җавап бирергә кирәк.

Биредә шулай ук халык музыка коралы думбрага аңлатма бирелә, бу эшне башкарганда думбра тавышы яздырылган аудио яки видеоязмадан файдаланырга мөмкин.

Тексттан аның әкияткә каравын күрсәтә торган урыннарны табу әкиятнең жанр хасиятләре турында беренче күзаллау булдыруга хезмәт итә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Биредә үз-үзеңә ышаныч хисенең әһәмиятен билгеләп, әңгәмә оештырырга мөмкин. Шулай ук әкият персонажы Гөлчәчәкнең алга таба дәреслек персонажларына кушылып китүен күрсәткән диалог белән дә таныштырабыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Әкиятнең ахырын укып килергә, сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кети-кети уйныйк әле

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – тапкырлык сыйфатына төшенү, авыр тормыш ситуациясеннән чыгу юлын таба белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; иҗади күзаллау, тамга-символик чараларны куллану, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Шүрәле» татар халык әкияте, «Карт һәм су анасы» нугай халык әкиятенең эчтәлеген белү, төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмала-

ры өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү «Гөлчәчәк» әкиятенең эчтәлеген сөйләү рәвешен ала.

Дәреслек персонажларының әңгәмәсе белән таныштырабыз. Шул вакытта Габдулла Тукайның шигыре искә төшерелә. Алмазның «Шүрәле дә әкияттә генә буламы?» дигән соравы проблемалы сорау буларак күзалланып, укучылардан альтернатив җаваплар алынуны күздә тота.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә Шүрәле турында сүз барачагын әйтәләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әкиятне уку барышында аңлашылмаган сүзләр барлана, аларның мәгънәләре ачыклана, текст буенча сорауларга җавап алына. Бу очракта видеодәрес материалын кулланырга мөмкин.

Әкияттә Шүрәленең тасвирламасы юк. Укучыларга аны үзләре күзаллаганча тасвирлап бирергә кушып була. Мисалга Габдулла Тукайның «Шүрәле» әкиятеннән өзекне укып китәргә дә мөмкин, татар иллюстраторларының Шүрәле сурәтләнгән рәсем-картиналарын күрсәтсәк тә яхшы була.

Тирәнтен өйрәнүчеләргә уйлануга этәрә торган проблемалы сораулар тәкъдим ителә, үзләренең фикерләрен белдерергә, позицияләрен ачыклатырга мөмкин.

Әсәрне анализланган соң, әкиятне рольләргә бүлеп укыйбыз.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләргә «Карт һәм су анасы» исемле нугай халык әкиятен укырга тәкъдим ителә. Әлеге әкият зур тәрбияви әһәмияткә ия. Ул еш кына аңлау өчен авыр булган *намус* төшенчәсен төшендерүдә отышлы. Укучылар аны әкияттә бәян ителгән вакыйгалар аша аңларга тиеш.

Әлеге әкият шулай ук укучыларның этномәдәни компетенцияләрен формалаштыруда зур роль уйный. Укучылар нугай халкының яшәү рәвеше, шөгыльләре белән танышалар. Дәреслектә урнаштырылган иллюстрация дә шул максатка хезмәт итә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Тирәнтен өйрәнүчеләрне Шүрәле турында фикерләшергә чакырып, «Былтыр кыстырганга, быел кычкырмыйлар» дигән әйтем белән таныштырып китәбез.

Бу урында Карурманның нинди булуын ачыкларга кирәк. Укучыларның аны нинди итеп күз алдына китерүләрен сорашабыз. Ахырда Шүрәле белән Карурман уенын уйнатып алу укучылар өчен кызыклы булачак. Карурман сүзеннән *кар, урман, урам, кан, кара, нар, карур, ару, ура* һ.б. сүзләрне аерып чыгарырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Әкиятләрне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә, бер әкият буенча рәсем ясарга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Әти-әни сүзен тыңламасаң…

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – әти-әни хакы, аларның сүзеннән чыкмау, тыңлау, хөрмәт итә белү төшенчәләрен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, төрле текстларны чагыштыру, текстларны чагыштыру

өчен нигезләр табу; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Казлар-аккошлар» рус халык әкиятенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

### I. Оештыру-мотивлаштыру.

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

### II. Актуальләштерү.

Өй эшен тикшерү: «Шүрәле», «Карт һәм су анасы» әкиятләренең эчтәлеген искә төшерү, идея-проблематикасы буенча сорауларга җавап бирү.

Әкиятләрдә очрый торган әкияти геройлар турында сорашып, әңгәмә үткәрәбез. Аларның аеруча еш очрый торганнарын барлыйбыз. Төрле халык әкиятләрендәге уртак геройларны ачыклыйбыз. Укучылар, алган белемнәренә таянып, Шүрәленең бары татар халык әкиятләрендә, ә Су анасының башка халыклар әкиятләрендә дә очравын билгелиләр.

Укучыларның игътибарын тагын бер әкияти персонажга – Убырлы карчыкка юнәлтәбез. Аның «Гөлчәчәк» исемле татар халык әкиятендә тасвирланышын искә төшерәбез, характерлы якларын ачыклыйбыз. Укучылар яхшы белгән рус халык әкиятләрендә дә мондый персонажның булуын, аның кем икәнлеген әйттерәбез.

Дәреслекнең 58 битендә бирелгән диалог белән таныштырабыз.

### III. Уку мәсьәләсен кую.

Укучылар, алдагы этапта сөйләшкәннәргә таянып, әлеге дәрестә укыласы әкиятнең герое Убырлы карчык булуын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әкият укыла, сүзлек эше үткәрелә, аңлашылмаган сүзләр ачыклана, аларга аңлатма бирелә. Сорауларга җавап биргәндә, эчтәлеккә игътибар ителә, проблемалы сорауларга җавап бирү барышында укучылар әкиятнең идея-проблематикасын билгелиләр: әкият өлкәннәрнең рөхсәтеннән башка ярамаганны эшләмәскә, әти-әни сүзеннән чыкмаска, аларның кушканнарын үтәргә чакыра.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әкияттәге герой-персонажларны барлап, Убырлы карчык образы турында аерым сөйләшүне оештырып була. Укучылар рус персонажы Баба-Яганың характерлы сыйфатларын әйтеп чыгалар. Аның татар әкиятләрендәге Убырлы карчык белән уртак һәм аермалы якларын билгелиләр.

**VI. Өй эше бирү.**

Әкиятне укырга, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә. Шулай ук рус һәм татар әкиятләрендәге Баба яга белән Убырлы карчык чагыштырып сурәтләнгән рәсемнәр ясарга кушып була.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Әкият ялган, тик шул хак: кемгә – уен, кемгә – сабак... (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – әкиятнең кеше тормышындагы урынына, әһәмиятенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару; бирелгән план нигезендә катлаулы булмаган кечкенә тикшеренү үткәрү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дөрес һәм дәлилле итеп әйтү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – белемнәрне, гомумиләштереп, системага сала алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Үткән дәрестә өйрәнелгәннәрне сораштыру.

«Әкият ялган, тик шул хак: кемгә – уен, кемгә – сабак» дигән темага сөйләшү үткәрелә. Әкиятнең кеше тормышындагы урыны ачыклана.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укытучы укучыларга дәрестә нәрсә эшләячәкләрен җиткерә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Дәрестә зур тема кысаларында өйрәнелгән әкиятләрне искә төшерү күздә тотыла. Дәреслектә сораулар бирелгән, аларга җавапларны укучылар укытучы белән бергәләшеп табалар. Укучы үз фикерен җиткергән вакытта дәлилләр, мисаллар китереп барса, бигрәк тә яхшы. Әкиятләргә иллюстрацияләр белән эшләгәндә, әкият исемнәрен генә әйтеп калмыйча, эчтәлекне искә төшерсәләр дә отышлы була.

Шулай ук бу дәрестә укучыларның алдан ук әзерләп килергә кушылган «Әкияттә кунакта» дип аталган проект эшләрен дә тәкъдим итеп була. Аны укучылар күмәк (парлап, төркем белән) эшләсәләр тагын да яхшы.

Ахырдан укучыларга Шүрәле белән уен кызыклы булачак. Уен барышында укучылар бирелгән сүзләр рәтендә теге яки бу әкияттә очраган сүзләрне билгеләп, артык сүзләрне күрсәтергә тиеш булалар.

**V. Өй эше бирү.**

Яратып укыган әкияткә рәсем ясарга һәм аның буенча сөйләргә әзерләнергә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Алтын тарак таптым

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – әкиятләрнең матурлыгын күрә белү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп җиткерү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Габдулла Тукайның «Су анасы» әкиятенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Әлеге этапта Алмаз, Гөлназ һәм Гөлчәчәкнең дәреслекнең 66 битендә бирелгән диалогын укырга мөмкин. Бу укучыларга алга таба уку мәсьәләсен куюда ярдәм итәчәк.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы һәм максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Биредә укучылар, иң элек, әкиятләрнең халык авыз иҗаты мирасы гына булмавын, ә аларның авторлары булуын аңларга тиеш. Әлеге темага кереп китү өчен Нур, Алмаз һәм Хөрмәтле Дәреслекнең сөйләшүеннән файдаланабыз.

Нәтиҗәдә укучылар автор әкиятләре төшенчәсе белән танышалар. Үзебез аңлатканнан соң гына, дәреслектәге автор әкиятенә бирелгән билгеләмәне укытырга мөмкин.

Нурның соравына җавап итеп, укучылардан (үзләре белгән) автор әкиятләренең исемнәрен әйттерергә була. Укучыларга татар халык әкиятләрен генә түгел, ә рус һәм башка халык әкиятләрен дә мисалга китереп булуын искәртәбез.

Дәрестә Габдулла Тукайның «Су анасы» әкият-поэмасы укыла. Биредә сүзлеккә игътибар итәргә кирәк. Аның шактый күләмле булуы балаларга күп кенә аңлашылмаган сүзләрнең күплеге белән аңлатыла.

Әкиятне укытучы укый башлый, ә алга таба текстны балалар үзләре укый. Әсәрне уку барышында комментарийлар биреп барырга кирәк. Соңыннан текст буенча сорауларга җавап бирү күздә тотыла. Бу очракта дәреслектә бирелгән сорауларны кулланып, шулай ук әсәрнең идея-проблематикасы белән бәйле башка сорау-биремнәрне тәкъдим итәргә мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Биредә эш малайның гамәлләре турында сөйләшеп, аларга бәя бирү рәвешен алырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Әкиятнең башын сәнгатьле итеп укырга, яттан сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Иясе юк әйбергә тимә, диләр

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – иясе юк әйбергә тияргә ярамаганлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗәләр формалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Габдулла Тукайның «Су анасы» әкиятенең эчтәлеген белү, әсәр буенча нәтиҗә чыгара белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерәбез. Әкиятнең беренче өлешенең эчтәлеген сөйләтәбез.

Игътибарны теманың исеменә юнәлтәбез, халыкның ни өчен шулай дию турында уйланабыз.

Дәреслек персонажларының әңгәмәсен укытабыз. Шулар нигезендә «Су анасының тарагы малайга ни өчен кирәк?» дигән проблемалы сорауга җавап эзләтәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Актуальләштерү этабында әйтелгәннәргә нигезләнеп, дәреснең максатын билгеләтәбез. Укучылар, проблемалы сорауга җавап таба алачакбыз, әкиятне укуны дәвам иттерәбез, дип фаразларга мөмкиннәр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

«Су анасы» әкиятенең дәвамын укыйбыз. Аңлашылмаган сүзләрне ачыклыйбыз. Әкиятне берничә тапкыр укытабыз. Тексттан соң бирелгән сораулар әкиятнең эчтәлеген ачыкларга да, төп фикерне билгеләргә дә, нәтиҗә чыгарырга да ярдәм итә.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр белән өстәмә сорауларга җавап биргәндә, теоретик белемнәр алуга басым ясап, әкиятнең формасына игътибар иттерәбез, әкиятнең, төре буенча, әкиятпоэма булуын бергәләп ачыклыйбыз.

Су анасы турында сөйләшү, аның турында белгәннәрне сораштыру, башка халыклар иҗатында әлеге образның кулланылышына игътибар иттерү урынлы да, кызыклы да булачак. Бу вакытта төрле иллюстрацияләр дә кулланырга мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укылган әсәр буенча белемнәрне ныгыту максатыннан кеше әйберенә тияргә ярамау, урлауның нәтиҗәсе турында әңгәмә оештырырга мөмкин. Укучылар бүгенге тормыш белән бәйләп сөйләсәләр, бигрәк тә яхшы.

Шулай ук әлеге этапта, вакыт калса, Су анасы мультфильмын карауны оештырырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Әкиятне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә, эчтәлеген сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Иләктә су тормый, ахмакта сүз тормый

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – сер тота белүнең әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, фаразлау, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя, фаразлау; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, алгоритм буенча эшли белү, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Абдулла Алишның «Сертотмас үрдәк» әкиятенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү. Уңай психологик халәт тудыру.

Сүзне әкиятләрнең безне нәрсәләргә өйрәтүе турында сорашудан башларга мөмкин.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларның фикерләренә нәтиҗә ясауга дәреслек персонажлары да кушылып китә: тема башында бирелгән әңгәмә укыла.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Әсәрне укый башлаганчы ук, исеменә игътибар иттерәбез, укылачак әсәрдә сүзнең нинди сыйфат турында баруын фаразлатабыз.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әкият ике өлешкә бүленеп, аны өйрәнүгә ике сәгать каралган. Беренче өлеше белән танышу традицион рәвештә – уку, беренчел тәэсирләр турында сораштыру, сүзлек, сорауларга җавап бирү рәвешен ала. Бу өлешне укыганда ук үрдәкнең үз-үзен тотышына игътибар иттерәбез, укучылар белән бергә аңа характеристика биреп карыйбыз. Бу беренче нәтиҗәне чыгарырга да ярдәм итәчәк.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әкиятнең бу өлешен рольләргә бүлеп укытып карарга була.

Шулай ук үрдәк белән алга таба нәрсә булачагын фаразлау әсәрне укуга кызыксыну уята һәм укучыларда регулятив универсаль уку гамәлләрен формалаштыру өчен нигез булып тора.

**VI. Өй эше бирү.**

Әсәрне укырга, планын төзеп сөйләргә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Серең эчеңдә торса, йортың тыныч булыр

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – сер саклауның әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләрен урнаштыру, нәтиҗәләр ясау; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Абдулла Алишның «Сертотмас үрдәк» исемле әкиятенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмала-

ры өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

*Сереӊ эчеӊдә торса, йортыӊ тыныч булыр* мәкале белән эшләү, укучыларның фикерләрен белешү.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: әкиятнең беренче өлешен план буенча сөйләтү. Әкият геройлары белән алга таба нәрсә буласын укучылардан фаразлату.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Гөлназ белән Айсылуның дәреслектәге диалогын укыту, дәрестә сүз нәрсә турында барачагын билгеләтү.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әкиятнең икенче өлеше укыла. Укытучы үзе укый башлый, укучылар дәвам итә. Тексттан соң бирелгән сораулар әкиятнең эчтәлеген ачуга да, геройларны характерлауга да юнәлдерелгән, биредә укучыларның үрдәккә мөнәсәбәтләрен төшенү дә мөһим. Бу очракта үрдәкне кызганыргамы, әллә ул тиешле җәзасын алганмы кебек сораулар биреп укучыларның бу турыда фикерләрен белешәбез. Әлбәттә, үрдәк кызгандыра. Ул үзенең сер тота белмәве аркасында харап була. Әгәр үрдәк кирәкмәс урында сөйләшеп йөрмәсә, серен саклый белсә, бу хәл булмый кала иде, дигән нәтиҗәгә киләбез.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләрнең сер саклауның нинди төшенчәләр белән бәйле булуын ачыклавы шушы сыйфат белән тәңгәллекләрне билгеләргә ярдәм итә, укучыларның логик фикерләвен үстерә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Предметның база өлешен генә өйрәнүчеләргә өзекне рольләргә бүлеп укырга тәкъдим итеп була.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләргә сер саклау, сер күтәрә алмау турында фикер алышу рәвешен алган әңгәмә дә оештырабыз. Бу вакытта дәреслектә тема ахырында бирелгән Гөлназ белән Гөлчәчәк диалогы ярдәмгә килә. Мондый әңгәмәне, мөмкинлек булганда, база өлешен генә өйрәнүчеләр өчен дә оештыра алабыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Әкиятне укып бетерергә, үзләре теләгән эпизод буенча рәсем ясарга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Әкиятләр илендә ниләр бар? (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – әкиятнең кешеләр өчен әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя, уку эшчәнлегенең уңышы һәм уңышсызлыгы сәбәпләрен билгеләү; гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз өлешеңә тигән эшне башкаруда җаваплылык хисе булдыру, үз фикерен дәлилләп әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – белемнәрне гомумиләштереп, системага сала белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Беренче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы:

**I. Оештыру-мотивлаштыру**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү**.

Өй эшен тикшерү: әкият турында сорауларга җавап бирү, андагы төп төшенчәләрне искәртеп барлау.

**III. Уку мәсьәләсен кую**.

Укучылар дәрестә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлаячакларын фаразлыйлар.

**IV. Белемнәрне ныгыту**.

Автор әкиятләренә һәм халык әкиятләренә багышланган зур темаларны кабатлау дәреслектә тәкъдим ителгән сорауларга җавап бирү рәвешендә үткәрелергә мөмкин. Шулай ук биремнәрне үтәүне дәрес-сәяхәт рәвешендә, һәр укылган әкияткә «кунакка кереп чыгып», төрле сорауларга җавап биреп оештырырга мөмкин. Бу вакытта дәреслектәге сорау-биремнәр ярдәмгә килә ала.

**V. Өй эше бирү.**

Яраткан китабың турында сөйләргә яки китапка реклама ясарга.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.
Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Кем нәрсә ярата?

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – бәхәсләшүнең аерым очракларда файдалы булуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйлә-

нешләре урнаштыру, нәтиҗә чыгару; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – «Кем нәрсә ярата» татар халык әкиятенең эчтәлеген белү, нәтиҗәләр чыгара белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

Дәреслекнең 4 нче битендә бирелгән шигырь белән таныштырабыз, шигырьнең эчтәлеге буенча әңгәмә үткәрәбез.

**II. Актуальләштерү.**

Бу дәрестә дәреслекнең икенче өлеше белән таныша башлыйбыз. Ул «Безнең нәни дусларыбыз» дип аталган зур тематик блоктан башлана. Дәреслек өлешләре арасында бәйләнеш булдыру өчен, беренче темага кергән вакытта «Кем нәрсә ярата?» исемле әкиятне өйрәнү күздә тотыла. Беренчедән, ул әкият жанрына карый, ягъни үткәндәге тема белән бәйләнеш урнаштырыла, икенчедән, хайваннар турындагы әкият булып, яңа теманы өйрәнүгә кызыксыну уята. Иң элек Алмаз, Гөлназ һәм Нурның теманың башында ук бирелгән әңгәмәсен укытабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәреснең темасын, максатын фаразлап әйтәләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әкиятне уку, аңлашылмаган сүзләрне барлау, мәгънәләрен ачыклау, текст буенча сорауларга җавап бирү күздә тотыла. Әкиятне анализлаганда, төрле хайваннарның төрле ризык яратула-

рына игътибар иттерәбез, тагын нәрсәләр белән тукклануларын ачыклатабыз. Коммуникатив максатны күздә тотып, башка йорт хайваннары турында сораштыру оештырабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бәхәсләшү, аның нинди гамәл булуы, файдасы яки зарары турында фикерләшеп алырга мөмкин.

Әкияттә диалоглар күп булу аны рольләргә бүлеп укырга мөмкинлек бирә.

**VI. Өй эше бирү.**

Әкияткә карата рәсем ясап килергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Югалган этне эзләп

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – мәрхәмәтлелек, теләктәшлек төшенчәләрен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; үз өлешенә тигән эшне башкаруда җаваплылык хисе булдыру, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Йолдыз Миңнуллинаның «Этем югалды бүген» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: әкият буенча ясалган рәсемнәрне карау, алар буенча сөйләү.

Укучыларның яраткан йорт хайваннары турында сөйләшү үткәреп була.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслектә бирелгән диалогны укыту, әсәрне кабул итәргә әзерләү, дәрес темасын һәм максатын билгеләү.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Йолдыз Миңнуллинаның «Этем югалды бүген» шигыре белән таныштыруны төрлечә оештырып була. Текстны укып чыгарга, электрон дәреслектәге аудиоязмадан да тыңлатырга мөмкин. Шулай ук видеодәрес материалын куллану отышлы. Сорауларга җавап бирү артык авырлык тудырмаячак, алар текстның эчтәлеген ачуга, геройларның хис-кичерешләрен билгеләүгә юнәлтелгән.

Сурәтләнгән ситуациядә кызның гаебе булу яки булмавын ачыклау проблемалы әңгәмәгә алып чыгачак.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Биредә Рөстәм Мингалимның «Дөньяда бер эт бар иде» исемле шигырен тыңлатырга мөмкин.

**Дөньяда бер эт бар иде**

Дөньяда
Бер эт бар иде –

Кечкенә,
Йомшак кына,
Ак кына,

Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.
Хуҗасы – шаян малай –
Этне ярата иде,
Аны ашата иде,
Ә бермәлне, нигәдер,
Яратмый да башлады.
Ашатмый да башлады.
Илтеп шәһәр эченә
Адаштырды ул аны,
Шушы көнне үк төнлә
Эте керде төшенә:
– Ашыйсы килде,
Кайттым, – ди.
Кечкенә, йомшак кына,
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.
Икенче көнне дә төнлә
Эте керде төшенә:
Бар ишектән аны тибеп
Чыгардылар кешеләр.
Иртүк торды да малай
Китте эзләргә этен.
Югалту ансат икән дә,
Аһ, читен табу, читен.
Эзли малай,

Тапмый этен.
Бик күптән инде менә.
Бик күптән инде һәр төндә
Эте төшенә керә:
Йөгереп керә,
Я тик тора, –
Кечкенә, йомшак кына,
Ак кына,
Тик маңгаенда
Кара тап бар чак кына.

*Рөстәм Мингалим*

Укучылар кешеләрнең төрле хайваннарга да мөнәсәбәтләре үзгә булуын билгелиләр, шигырь героеның гамәлләрен бәялиләр. Әлеге хәлнең һәм «Этем югалды бүген» шигыренең героинясы белән булган ситуациянең укучыларга таныш яки таныш булмавы ачыклана, алар бу хәлләргә карата үз фикер-бәяләрен җиткерәләр.

Алга таба дәреслек персонажларының Алиянең этен табу эшенә кереп китүе турында диалог бирелә. Этнең югалуы турында игълан язу укучылар өчен кызыклы эш булачак.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Әйдәле, Акбай! Өйрән син!

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – дуслыкның көчен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Роберт Миңнуллинның «Акбайга» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү.

Дәреслекнең 12 нче битендә урын алган персонажларның әңгәмәсе белән танышабыз. Алдагы дәрестә югалган этне эзләү турында игълан язып, Гөлчәчәк аның нәтиҗәләрен дусларыннан сораштыра. Бу укучыларга кызык булачак, этнең табылуы һәм иясенә тапшырылуы аларда шатлану хисе уятачак.

Алга таба Алмазның Акбайны өйрәтүенә багышланган диалог урнаштырылган. Рәсемгә дә игътибар иттерәбез. Шигырьнең авторы Габдулла Тукай булуын искәртәбез.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә сүзнең дүрт аяклы дусларыбыз – этләр турында барачагын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Роберт Миңнуллинның «Акбайга» шигыре сәнгатьле итеп укыла, укучылар аны башта укытучы башкаруында тыңлыйлар, аннан соң үзләре укыйлар. Аңлашылмаган сүзләрнең мәгънәләре, тәрҗемәләре белән таныштырабыз.

Текст буенча сорауларга җавап биргәндә, юлбарыска охшаган песине тасвирларга кушабыз. Акбайга да характеристика бирергә онытмыйбыз. Соңгы сорау проблемалы булып, укучыларның аңа төрлечә җавап бирүләренә ирешәбез.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Эт белән песинең үзара мөнәсәбәтләре турында әңгәмә оештырып була. Проблемалы сорау, мәкаль-әйтемнәр мәсьәләне ачыкларга ярдәм итә. Гөлназның һәм Актүш белән Актырнакның

дуслык тарихы бик кызыклы. Укучылар тормыштан үз мисаллары китерергә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Бәхетле песи

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – песиләрне ярату, аларга карата теләктәшлек һәм мәрхәмәтлелек хисләре туу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы һәм төгәл булмаган мәгълүматны танып белү; әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Нәкыйп Каштановның «Йөнтәс песи баласы» хикәясенең эчтәлеген белү, төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

### Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: Йолдыз Миңнуллинаның «Этем югалды бүген» шигырен сәнгатьле укыйлар, әсәрнең эчтәлеге, идея-

проблематикасы буенча сорауларга җавап биреп, үткән материалны кабатлыйлар.

Алга таба дәреслекнең 16 битендә бирелгән диалог белән таныштырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Алдагы этапта эшләнгәннәр уку мәсьәләсен билгеләргә ярдәм итәләр, укучылар әлеге дәрестә нәрсә эшләячәкләрен ачыклыйлар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Нәкыйп Каштановның «Йөнтәс песи баласы» хикәясе белән танышу. Текстны укып чыгарга, электрон дәреслектәге аудиоязмадан тыңлатырга да мөмкин. Шулай ук видеодәрес материалын кулланырга була. Тексттан соң бирелгән сорауларның зур өлеше әсәрнең эчтәлеген ачыклауга юнәлтелгән.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр өчен эзләнүгә нигезләнгән проблемалы сораулар тәкъдим ителә.

Сүз белән эшне күздә тоткан 10 нчы сорау язучының мәсьәләгә карата фикерен ачыкларга ярдәм итә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Программа сурәтләү чарасы буларак чагыштыруны үзләштерүне күздә тота. Бу төшенчәне тәкъдим итү алдыннан 11 нче сорауга җавап бирергә кушыла. *Песи йомгактай бөтерелә* дигән җөмләгә игътибар итеп, укучылар песинең ни өчен йомгак белән чагыштырылуын ачыкларга тиеш булалар.

Аларның фикерләрен раслап, Нурның сүзләре укыла.

Алга таба чагыштыру төшенчәсенә билгеләмә бирәбез. Бу очракта дәреслектәге материалны файдаланырга мөмкин. Хөрмәтле Дәреслекнең биремен үтибез, ягъни укучылар чагыштыруга мисаллар китерергә тиеш булалар.

Гөлназның песи ялгыз калып, аны беркем дә өенә алып кайтып китмәсә, ул нишләр? дигән соравына җавап биреп фаразлатырга мөмкин.

Аннан соң Нурның нәтиҗәсен укытабыз.

**VI. Өй эше бирү.**

Хөрмәтле Дәреслек биргән биремне өйдә үтәргә, ягъни песигә кушамат уйлап, аның кыз өендәге бәхетле тормышын сурәтләгән рәсем ясап килергә кушабыз.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Тәрбиягә песи алдым

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – миһербанлы булу төшенчәсенең асылына төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Әминә Бикчәнтәеваның «Сөйкемсез песи» хикәясенең эчтәлеген белү, Муса Җәлилнең «Карак песи» шигыре буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Дүрт аяклы дуслар – этләр, мәчеләр турында сөйләшүебезне дәвам итәбез. Әңгәмәне үткән дәрестә укылган хикәягә нигезләнеп алып барып була. Өй эшенә песигә исем табып, рәсем ясап ки-

ләргә кушылган булса, шулар турында сораштырабыз. Рәсемнәр буенча сөйләтәбез.

Биредә Алмаз белән Гөлчәчәкнең диалогы белән таныштырабыз, Лилия Вергазованың Йомгак исемле песи турындагы хикәясеннән өзек укытабыз. Песиләргә, этләргә кушамат тагу турында нәтиҗә ясатабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Диалогны дәвам итеп, песиләрнең төрле булуы – ягымлы һәм сөйкемсез песиләр турындагы фикер аша дәрестә нәрсә турында сүз барачагын билгеләтеп була.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Әминә Бикчәнтәеваның «Сөйкемсез песи» хикәясе белән таныштырабыз. Песиләр нинди генә булмасын, без аларга карата миһербанлы булырга, аларны яратырга, тәрбияләргә тиеш. Бу хикәя шул турыда онытырга ярамавын искәртә.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләргә бу дәрес кысаларында тагын бер әсәр – Муса Җәлилнең «Карак песи» шигырен өйрәнү каралган. Бу очракта песиләрнең нәрсә белән тукลануын, аларның нәрсә яратуларын ачыклыйбыз. Безгә дәреслектәге материал ярдәмгә килә ала.

Шигырь укыла, сорауларга җавап бирелә. Песине хыянәтче дип әйтеп буламы, юкмы, дигән проблемалы сорау куела. Ул укучыларны уйландыра, аларның бу персонажга карата фикерләрен ачыкларга ярдәм итә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Йортта төрле хайваннар тотуның үзенчәлекләре турында сөйләшеп була. Барыннан да элек җаваплылыкның әһәмиятен онытмау турында аңлатырга кирәк.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, яраткан йорт хайваны турында сөйләргә әзерләнергә, Муса Җәлилнең «Карак песи» шигырен ятларга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Безнең кошчыклар

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – кошлар, аларны саклау, аларга ярдәм итүнең әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Лиана Әмирхanованың «Минем нәни дусларым» шигыренең, Фоат Садриевның «Сары чәчкәләр» хикәясенең эчтәлеген белү, төп фикерне билгели алу.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: укучылар яраткан йорт хайваннары турында язган хикәяләре белән таныштыралар. Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр Муса Җәлилнең «Карак песи» шигырен яттан сөйлиләр.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәреслектә бирелгән диалогны укып, дәрестә сүз кошлар турында барачагын билгели алачаклар.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Лиана Әмирханованың «Минем нәни дусларым» шигыре белән танышу. Текстны үзең укып чыгарга, электрон дәреслектәге аудиоязмадан тыңлатырга, берничә укучыдан укытырга мөмкин. Шигырьдән алган беренче тәэсирләрне уртаклашабыз. Тексттан соң бирелгән сораулар артык авыр түгел, соңгы 5 нче сорау укучыларда регулятив универсаль уку гамәлләре формалашуны, ягъни фаразлауны күздә тота. Алга таба дәреслек персонажларының диалогы аша база өлешен өйрәнүчеләр генә үзләштерелергә тиешле сынландыру (җанландыру) сурәтләү чарасы белән таныштырабыз. Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр әлеге төшенчә белән 2 нче сыйныфтан ук таныш, бу очракта алар өчен дә кабатлау, белемнәрне ныгыту артык булмас.

Сурәтләү чарасы буларак сынландыруны үзләштерү билгеләмә белән танышуны, Хөрмәтле Дәреслекнең биремен үтәүне күздә тота.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләр бу дәрес кысаларында Фоат Садриевның «Тургай» повестеннан алынган «Сары чәчкәләр» исемле өзекне укырга тиеш булалар. Дәрестә өлгермәгән очракта өйдә укып килергә кушыла.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Әлеге этапны кошларны кайгырту турында сөйләшү рәвешендә үткәрергә мөмкин. Безгә дәреслек персонажлары – Гөлчәчәк, Гөлназ, Алмазның диалогы ярдәмгә килә ала.

Предметны тирәнтен өйрәнүчеләргә «Сары чәчкәләр» хикәясеннән соң бирелгән табышмакларны чишү кызыклы булачак.

**VI. Өй эше бирү.**

«Безнең нәни дусларыбыз» шигырен сәнгатьле укырга, йорт кошлары турында хикәя төзергә, дәреслектә бирелгән мәкальләр белән танышып, аларның кайсы очракларда кулланылуын ачыклауны өй эше итеп бирергә мөмкин.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Миһербанлы булыйк! (Кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – хайваннарга, кошларга карата миһербанлы, шәфкатьле булу зарурлыгын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен дәлилле әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – белемнәрне гомумиләштерә, системага сала белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Укучыларны дәреслекнең 50 нче битендә бирелгән кереш сүз белән таныштырабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Теманы гомумиләштереп кабатлау сорауларга җавап бирү рәвешендә була ала. Укучылар сорауларга тема кысаларында өйрәнелгән әсәрләргә нигезләнеп җавап бирәләр, нәтиҗә ясыйлар.

Әлеге дәрес кысаларында «Безнең нәни дусларыбыз» исемле проект эшләрен яклатабыз (предметны тирәнтен өйрәнүчеләр өчен).

Дәреслектә, теманы йомгаклап, Мәхмүт Хөсәеннең «Безнең дусларыбыз» шигыре бирелгән. Аны укучылардан укытабыз. Шигырьдә телгә алынмаган йорт хайваннарының рәсемен ясарга тәкъдим итеп була. Аны өй эше итеп бирергә дә ярый.

Гөлназның китапханәсе белән танышу алга таба китаплар укуга кызыксыну уятырга тиеш.

**V. Өй эше бирү.**

Йорт кошларының холыклары турында зур булмаган хикәя төзергә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Дуслык – зур байлык

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – дуслыкның мәгънәсенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру мөстәкыйль рәвештә тексттан кирәкле мәгълүматны таба белү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә язма һәм телдән текст булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Мәрьям Галләмованың «Дуслар» хикәясенең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру. Әдәп, тәрбиялелек яки дуслык турында мәкаль мисалында, аның мәгънәсен аңлатырга була.

**II. Актуальләштерү.**

«Изге сүз, якты йөз» дип аталган тематик блокны өйрәнүне дуслык турында сөйләшүдән башлыйбыз. Шул ук вакытта алдагы зур тема кысаларында сөйләнгәннәр белән дә бәйләнеш булдырырга омтылып, табигать һәм кеше арасындагы дуслык турында искәртәбез. Дәреслектән шул турыда сөйләүче персонажлар әңгәмәсен укытабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар дәрестә сүзнең хайваннар белән кешеләр арасындагы дуслык турында баруын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Дәрестә Мәрьям Галләмованың «Дуслар» исемле хикәясе белән танышу күздә тотыла. Әсәр зур түгел, шуңа күрә аны аңлау да, анализлау да авыр булмаячак. Хикәянең эчтәлеген сөйләгәннән соң, Кәримгә һәм Актырнакка характеристика бирергә тәкъдим итәбез. Кәримнең мәрхәмәтле, яхшы күңелле, башкаларның хәлләренә керә торган малай булуын билгеләтәбез. Укучылар Актырнакның да тугры дус, куркусыз эт булып сурәтләнүен ассызыклыйлар.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Нурның «Эт иярткән – иптәшле» мәкале нигезендә сөйләшү үткәрәбез.

Шулай ук бу этапта тирәнтен өйрәнүчеләр өчен Валентина Осееваның «Кем хуҗа?» исемле хикәясен укырга тәкъдим ителә. Әсәрне укыганнан соң, фикер алышып була.

**VI. Өй эше бирү.**

«Дуслык – зур байлык» темасына зур булмаган хикәя язарга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Изге сүз

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – олыларга хөрмәт хисе булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗәләрне формалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикереңне дөрес һәм дәлилле итеп әйтү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Дания Гайнетдинованың «Изге сүз» хикәясенең эчтәлеген белү, төп фикерне билгеләү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай эмоциональ халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: укучыларның әзерләп килгән «Дуслык – зур байлык» темасына язып килгән хикәяләрен укытабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасын, максатын билгеләү өчен персонажларның 43 биттә бирелгән диалогын укытырга мөмкин. Ул дәрестә нәрсә турында сүз барачагын билгеләргә ярдәм итәчәк.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Укучылар Дания Гайнетдинованың «Изге сүз» хикәясе белән танышалар. Текстны укып чыгарга, электрон дәреслектәге аудиоязмадан тыңлатырга да мөмкин. Шулай ук видеодәрес материалын кулланырга була. Алга таба чылбырлап укуны эшкә җигә алабыз. Хикәядән алган беренче тәэсирләрен уртаклашабыз. Текст белән эшләгәндә дә дәреслектә бирелгән сорау-биремнәрне кулланып була. Иң мөһиме – текстта бирелгән, автор әйтергә теләгән төп фикерне билгеләү.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Бу әсәр зур тәрбияви әһәмияткә ия. Бүгенге көндә яшьләр арасында каты күңеллелек, ваемсызлык, салкынлык, шуның нәтиҗәсендә өлкәннәргә хөрмәт хисенең кимеп баруы күзәтелә. Мондый мөнәсәбәт җәмәгать транспортында да сизелә. Бу өлкән яшьтәгеләргә, инвалидларга, балалы кешеләргә урын бирмәүдә ачык чагылыш таба. Әлеге проблеманы хәл иткәндә мәктәптә эзлекле эш алып бару мөһим. Дания Гайнетдинованың хикәясе бу мәсьәләгә беркадәр ачыклык кертә, балаларны дөрес тәрбияләүгә юнәлеш бирә. Шуңа күрә әсәрне анализлаган вакытта әлеге моментны кат-кат искәртергә кирәк. Бу турыда әңгәмәне дәреслек персонажларының диалогыннан башлыйбыз, укучылар фикерләшүләрен дәвам итәләр.

Сөйләшкәннәргә нәтиҗә ясап, Ринат Мәннанның дәреслектәге «Алга утырсаң» исемле шигырен укыйбыз, аның эчтәлеге буенча сораулар бирәбез, укучылардан бу мәсьәләгә карата фикерләрен сорашабыз.

Тема ахырында «Сабантуй бүләге» рәвешендә бирелгән мәкаль дә безнең фикеребезне расларга ярдәм итә.

**VI. Өй эше бирү.**

Хикәяне укырга, эчтәлеген сөйләргә өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Яхшы сүз – җанга рәхәт, яман сүз – җанга җәрәхәт

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр –рәхмәт* сүзенең тормыштагы урынын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Идрис Туктарның «Рәхмәт һәркем өчен рәхәт» хикәясенең, Хәкимҗан Халиковның «Якты сүз» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Алдагы дәрестә бирелгән өй эшен тикшерү. Дания Гайнетдинованың «Изге сүз» хикәясен искә төшерәбез. *Рәхмәт* сүзе турында сөйләшүне дәвам итеп, аның нинди мәгънәләр аңлатуын, кайсы сүзләр белән характерлануын ачыклыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслек персонажлары диалогы укучыларга дәреснең эчтәлеген мөстәкыйль фаразлап ачыкларга мөмкинлек бирә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Идрис Туктарның «Рәхмәт һәркем өчен рәхәт» хикәясе укыла. Электрон дәреслектә бирелгән аудиоязманы да тыңлатырга мөм-

кин. Текст буенча сорауларга җаваплар алына. Хөрмәтле Дәреслек һәм Нурның нәтиҗәсен укыйбыз.

Хәкимҗан Халиковның «Якты сүз» шигыре рәхмәт турында. Бу шигырь ярдәмендә укучыларга тагын бер кат *рәхмәт* сүзенең нинди зур әһәмияткә ия булуын төшендерә алабыз. Шигырь укыла, аның буенча сорауларга җавап бирелә. Бу вакытта әсәрнең эчтәлеге билгеләнә. Сорауларга җавап биргәндә, укучыларның игътибарын *рәхмәт* сүзен билгеләүче сыйфатларга юнәлтү мөһим.

*Рәхмәт* сүзен характерлаган сүзләрне күрсәтеп, сурәтләү чарасы буларак *эпитетка* аңлатма бирү артык авыр булмаячак. Укучылар үзләре үк бу сыйфатларның сурәтләү мөмкинлегенә ия булуын күрәләр. Үз фикерләрен дәреслектә бирелгән билгеләмә нигезендә ныгыталар, эпитетларга мисаллар китерәләр.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучыларның *рәхмәт* сүзенә мөнәсәбәтен ачыклау да бик мөһим. Бу очракта аларны, *рәхмәт* сүзен әйтү зарурлыгын аңлату өчен, әңгәмәгә тарта алабыз. Алмаз белән Гөлназның дәреслектә бирелгән диалогы шул әңгәмәнең башы булып тора ала.

*Рәхмәт* сүзенең бердәнбер тылсымлы сүз түгеллеген аңлату өчен, 52–53 битләрдәге Мансур турындагы хикәяне укытабыз. Хөрмәтле Дәреслекнең хикәянең ахырындагы сүзләре проблемалы ситуация тудыра. Укучылар аны чишү барышында үз фикерләрен җиткереп, ахырдан нәтиҗә ясарга тиеш булалар.

**VI. Өй эше бирү.**

*Рәхмәт* сүзе, аның әһәмияте турында зур булмаган хикәя язарга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Ничек яхшы булырга

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – яхшылыкны яманлыктан аера белү, тормышта яхшы булырга кирәклеген аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗәләр формалаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә телдән һәм язма текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – Равил Фәйзуллинның «Ничек яхшы булырга?» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эше тикшерү: *рәхмәт* сүзе, аның әһәмияте турында хикәяләрне тыңлау.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреслектәге тема башындагы бирелгән Алмазның соравы укучыларны уйлануга этәрә һәм дәреснең максатын билгеләргә ярдәм итә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Алмаз биргән сорауга Равил Фәйзуллинның «Ничек яхшы булырга?» дип исемләнгән шаян шигыре дә җавап бирә ала. Текстны укып чыгарга, яки электрон дәреслектәге аудиоязмадан тыңлатырга да мөмкин. Шулай ук видеодәрес материалын кулланырга була. Шигырь тексты буенча сорауларга җаваплар алабыз.

Яхшы булу турында теманы дәвам итеп, предметны тирәнтен өйрәнүчеләр бу дәрес кысаларында Рафис Гыйззәтуллинның «Кеше әйбере» исемле хикәясен укый алалар. Хикәя дәреслек персонажларының яхшы һәм начар гамәлләр турындагы диалогы белән таныштырганнан соң укыла, сүзлек эше үткәрелә, сорауларга җаваплар алына. Гөлназ белән Нурның хикәядә күтәрелгән мәсьәләгә карата фикерләре дәреснең нәтиҗәсе була да.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Дәреслектә Хәкимҗан Халиковның яхшылык турындагы тизәйткече бирелә, шуның белән танышып, сөйләм үстерү өстендә эшләргә мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

«Ничек яхшы булырга?» темасына зур булмаган хикәя төзеп килергә. Равил Фәйзуллинның «Ничек яхшы булырга?» шигырен ятларга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Яхшылык эшләргә ашык! (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – әдәплелек кагыйдәләрен белеп, *изге сүз* төшенчәсенең мәгънәсенә төшенү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, нәтиҗә чыгару; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү, сөйләм ситуациясе нигезендә язма һәм телдән текстлар булдыру.

*Предмет нәтиҗәләр* – теманы гомумиләштерә, белемнәрне системага сала белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмала-

ры өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Тема башында Хөрмәтле Дәреслекнең сүзләре дәресне актуальләштерә, алга таба укучыга уку мәсьәләсен тәгъбир итәргә ярдәм итә.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең максаты билгеләнә.

**IV. Белемнәрне ныгыту.**

Теманы гомумиләштереп кабатлау сорауларга җавап бирү рәвешендә бара. Укучылар сорауларга тема кысаларында өйрәнелгән әсәрләргә нигезләнеп җавап бирәләр, нәтиҗә ясыйлар.

Дәреслектә, теманы йомгаклап, Фирая Бәдретдинованың «Хәерле иртә! Хәерле көн! Хәерле кич! Тыныч йокы!» исемле хикәясе бирелгән, шуны укырга тәкъдим итәбез. Биредә тәмле сүзләр буларак саналган *хәерле иртә, хәерле көн, хәерле кич, тыныч йокы* сүзләренең әһәмиятен билгеләтәбез, аларны куллану ситуацияләрен ачыклыйбыз.

Гөлназның китапханәсе белән танышу укучыларда алга таба китап укуга кызыксыну уятырга тиеш.

**V. Өй эше бирү.**

Үзеңә ошаган бер «тәмле» сүз белән хикәя төзергә.

**VI. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Хәрәкәттә – бәрәкәт

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – зарядка ясау – сәламәт яшәүнең бер таләбе булуын аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – укытучы ярдәмендә максатны формалаштыру, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилле әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Хәкимҗан Халиковның «Хәрәкәттә – бәрәкәт» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Зарядка ясатып алырга мөмкин. Балалардан иртән зарядка ясау-ясамаулары турында сорашып була.

**II. Актуальләштерү.**

Бу дәрестә спорт, сәламәт яшәү рәвеше турындагы зур тематик блокны өйрәнү башлана. Беренче дәрестә зарядка ясауның мөһимлеге турында сүз барачак. Темага алып керү, укучыларга уку мәсьәләсен тәгъбир итәргә җиңелрәк булсын өчен, дәреслек персонажларының әңгәмәсе белән таныштырабыз. Укучыларның шул әңгәмәгә кушылып китүе, үз фикерләрен белдерүе дә кирәк.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәреснең темасы ачыклана, максатлары билгеләнә.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Төп өлештә Хәкимҗан Халиковның «Хәрәкәттә – бәрәкәт» шигыре өйрәнелә. Текстны укып чыгарга, электрон дәреслектән аудиоязмадан тыңлатырга да мөмкин. Шулай ук видеодәрес материалын кулланырга була. Сүзлек эше үткәргәннән соң, укучылардан шигырьне тагын берничә мәртәбә укытабыз. Әсәр эчтәлеген, төп фикерен ачыклауда дәреслектәге сорау-биремнәр дә ярдәм итә. Биредә *хәрәкәттә – бәрәкәт* гыйбарәсен укучыларның ничек аңлауларын ачыкларга кирәк. Аны база өлешен генә өйрәнүче укучылар аңлап бетермәскә дә мөмкин.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучылардан иртән ничек зарядка ясаулары турында сөйләтеп була. Бу вакытта укучыларларның төрле сүзләр, төзелмәләр кулланып сөйләвенә басым ясыйбыз.

Алга таба Алмазга бирәсе киңәшләрне тыңлатабыз.

Зарядка ясау кагыйдәләрен искәртеп, дәреслектән Мансур турындагы хикәя укыла. Аның гамәлләренең дөреслеге яки дөрес түгеллеге ачыклана. Хикәягә исем уйлау да укучы өчен кызыклы булачак.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне сәнгатьле итеп укырга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Шәп дәрес – физкультура

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – физкультура дәресенең әһәмиятен аңлау, аның башка дәресләр арасында урынын билгеләү.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – фаразлау, уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; мәгълүмат алу, тамга-

символик чараларны куллану, сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Җәүдәт Дәрзаманның «Бар да җитез», Роберт Миңнуллинның «Тәнәфес» шигырьләренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирә белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерәбез – Хәкимҗан Халиковның «Хәрәкәттә – бәрәкәт» шигырен берничә укучыдан сәнгатьле итеп укытабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Дәрестә физультура дәресе һәм тәнәфестә вакытны файдалы үткәрү турында сүз барачак. Бу очракта безгә персонажларның сөйләшүе ярдәмгә килә. Шуннан чыгып, укучылар дәрестә сүзнең нәрсә турында баруын билгелиләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Җәүдәт Дәрзаманның «Бар да җитез» исемле шигыре белән таныштырганда, аудиоязма тыңлатырга мөмкин. Шуннан соң әсәрдән алган беренче тәэсирләр турында сорашабыз. Дәреслектәге рәсемнәр шигырьдә нәрсә турында сүз баруын күз алдына китереп бастыра, иллюстрация буенча сөйләгән вакытта укучыларның коммуникатив күнекмәләре формалаша.

Татар мәктәбендә укучыларга Роберт Миңнуллинның программа нигезендә «Күңелле тәнәфес» шигыре тәкъдим ителә.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Укучыларның физкультура дәресенә мөнәсәбәтләрен белү максаты белән әңгәмә оештырырга мөмкин.

Гөлназның баскетбол уены турында сөйләве укучыларның танып белү күнекмәләрен арттыра, дөньяны күзаллауларын киңәйтә. Элек ничек уйнаганнар? Хәзер ничек?

Укучылар физкультура булмаган көнне дә тәнәфестә актив яшәү рәвеше, хәрәкәтләнү белән шөгыльләнергә мөмкин булуын аңлыйлар. Укучылардан тәнәфестә нәрсәләр белән шөгыльләнүләрен сораштырабыз. Дәреслектән тәнәфестә уйнап була торган хәрәкәтле уеннар турында укытабыз. Кайберләрен балалар белән шунда ук уйнап та алырга мөмкин.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьләрне сәнгатьле итеп укырга өйрәнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Витаминлы хәрефләр, хәрефле витаминнар

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – витаминнарның, дару үләннәренең, аларны куллана белүнең әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, мөстәкыйль рәвештә яисә укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы һәм төгәл булмаган мәгълүматны танып белү, нәтиҗә чыгару; диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Шәүкәт Галиевнең «Витаминлы хәрефләр» шигыренең, Вахит Имамовның «Шифалы табиблар» хикәясенең эчтәлеген белү, алар буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

**Дәрес барышы**

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Витаминнар яки берәр файдалы үсемлек турында сөйләргә, яки видеоязма карарга, аларның кеше сәламәтлеге өчен әһәмиятен ачыкларга мөмкин.

**II. Актуальләштерү.**

Нур, Алмаз һәм Гөлназның тема башындагы диалогын укыйбыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

«Витаминнар ни өчен кирәк?» дигән сорау белән теманы өйрәнүгә кызыксыну тудырабыз һәм уку мәсьәләсен билгеләтәбез.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Шәүкәт Галиевнең «Витаминлы хәрефләр» шигырен укып чыгабыз, электрон дәреслектәге аудиоязмадан тыңлатырга да мөмкин. Шулай ук видеодәрес материалын кулланырга була. Шигырь тексты буенча сорауларга җаваплар алына. Укучылардан нинди витаминнар эчүләре турында сораштыра алабыз. Аларның файдасы турында әңгәмә оештырабыз.

Вахит Имамовның «Шифалы табиблар» дип исемләнгән күләме ягыннан зур булмаган, ләкин эмоциональ-экспрессив, танып белү мәгълүматына бай әсәре белән танышабыз. Укучылар текст буенча сорауларга җавап бирәләр, әсәрнең эчтәлеген ачыклыйлар.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Шулай ук биредә Вәсимә Хәйруллинаның «Шифа чәе» исемле шигырен укыту да урынлы. Ул төп өлештә өйрәнелгәннәрне тагын бер кат ныгытырга ярдәм итә. Дәреслектә шулай ук, этнографик материал буларак, Болгардагы «Табиб йорты» белән таныштыру да күздә тотыла. Укучылар аның турында мәгълүмат белән танышалар, фоторәсемнәр карыйлар. Болгардагы «Табиб йорты»н күргән укучылар үз тәэсирләре белән уртаклашалар.

**VI. Өй эше бирү.**

Берәр витамин яки файдалы үлән турында кыска гына чыгыш әзерләргә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Үрнәк алабыз

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – спорт белән шөгыльләнүнең әһәмиятен аңлау, илебезнең, республикабызның данлыклы спортчыларына хөрмәт белән карау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, мөстәкыйль рәвештә яисә укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы һәм төгәл булмаган мәгълүматны танып белү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Сания Әхмәтҗанованың «Үрнәк алыйк» шигыренең эчтәлеген белү, аның буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерәбез. Витамин яки файдалы үлән турында чыгышларны тыңлыйбыз.

Гөлназ белән Алмазның тема башындагы диалогы белән танышабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар, актуальләштерү этабында әйтелгәннәргә нигезләнеп, уку мәсьәләсен тәгъбир итәләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Сания Әхмәтҗанованың «Үрнәк алыйк» шигырен уку. Укытучы шигырьне сәнгатьле итеп укый, укучылардан беренче тәэсирләрен сораша. Сүзлек эше үткәрелә. Алга таба берничә укучыдан укыта. Сорауларга җавап биргәндә республикабыз данын яклаган спортчылар турында сөйләсәк яхшы була. Фоторәсемнәр күрсәтеп, аларның нинди спорт төрендә уңышка ирешүләре белән таныштырабыз. Укучылар үзләре белгән башка, хәзерге заман спортчыларын да барлыйбыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Шигырьдә спортның шахмат төре турында сүз бара. Шуңа аңлатма бирү сорала. Күп кенә балалалар аның спорт төренә каравын белмиләр. Бу очракта дәреслек персонажларының диалогы ярдәмгә килә. Сыйныфта шахмат белән шөгыльләнүчеләр булса, алардан сөйләтә алабыз. Нәтиҗә ясап, предметны тирәнтен өйрәнүчеләргә Заһирә Гомәрованың «Чемпион» исемле шигырен укытабыз. База өлешен өйрәнүчеләргә дә, мөмкинлек бирелгәндә, бу шигырьне укырга тәкъдим итеп була.

**VI. Өй эше бирү.**

Шигырьне ятларга.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Спорт иле – Татарстан

**Планлаштырылган нәтиҗәләр:**

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – спорт белән шөгыльләнүнең әһәмиятен аңлау, республикабызга мәхәббәт һәм хөрмәт хисе булу.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; сәбәп-нәтиҗә бәйләнешләре урнаштыру, мөстәкыйль рәвештә яисә укытучы тәкъдим иткән тикшерү ысулы нигезендә ышанычлы һәм төгәл булмаган мәгълүматны танып белү; әңгәмәдә катнашу, үз фикерен әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – Йолдыз Шәрәпованың «Татарстан – спорт иле», Галимҗан Гыйльмановның «Универсиада» шигырьләренең эчтәлеген белү, алар буенча сорауларга җавап бирү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова, Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part2/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр, видеоролик.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру.**

Исәнләшү.

Уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү.**

Өй эшен тикшерү: ятлаган шигырьне тыңлау.

Хөрмәтле Дәреслекнең тема башындагы сүзләре белән танышабыз.

**III. Уку мәсьәләсен кую.**

Укучылар, актуальләштерү этабында әйтелгәннәргә нигезләнеп, уку мәсьәләсен тәгъбир итәләр.

**IV. Уку мәсьәләсен адымлап чишү.**

Йолдыз Шәрапованың дәрестә өйрәнеләчәк «Татарстан – спорт иле» шигырен электрон дәреслектәге аудиозмадан да тыңлатырга мөмкин. Шулай ук видеодәрес материалын да өлешләп кулланырга була. Беренче тәэсирләр белән уртаклашканнан соң, шигырьне берничә укучыдан укытабыз. Сорауларга җавап биргәндә дәреслектәге сорау-биремнәрне дә онытмыйбыз. Татарстанда нинди спорт төрләренең аеруча популяр булуы, бу өлкәдәге уңышлар турында сораша алабыз.

Бу дәрестә тагын бер әсәрне өйрәнү каралган. Галимҗан Гыйльмановның «Универсиада» исемле шигырен укыганда 2013 елда Татарстанда үткән әлеге зур бәйге турында фикер алышабыз.

**V. Белемнәрне беренчел ныгыту.**

Татарстанда киң таралган спорт төре – татарча көрәш турында сөйләшү үткәрергә мөмкин. Карл Фуксның дәреслектә урын алган язмасыннан бу бәйгенең ничек үтүен белеп була.

**VI. Өй эше бирү.**

Үзең яраткан спорт төре турында сөйләргә әзерләнергә.

**VII. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

**Тема**: Сәламәт яшибез, спорт белән шөгыльләнәбез (кабатлау)

**Планлаштырылган нәтиҗәләр**:

*Шәхескә кагылышлы нәтиҗәләр* – спортның кеше тормышындагы, аның төрле яклап үсешендәге әһәмиятен аңлау.

*Метапредмет нәтиҗәләр* – уку мәсьәләсен куя белү, иптәшләренең җавапларын бәяләү, үзбәя; гомумиләштерү ясау, нәтиҗәләр формалаштыру; әңгәмәдә катнашу, диалог һәм әңгәмә алып бару кагыйдәләрен үтәү, үз фикерен дәлилле әйтә белү.

*Предмет нәтиҗәләр* – белемнәрне гомумиләштереп, системага сала белү.

**Материал:** Электрон дәреслек: Әдәби уку. 3 нче сыйныф. Ике кисәктә. Икенче кисәк: башлангыч гомуми белем бирү оешмалары өчен дәреслек (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) / Г.Н. Мөхәрләмова Д.М. Абдуллина. – Казан, 2023 / http://litcorpus.antat.ru/ADABI_UKU/3snf/part1/

**Җиһазлау:** проектор, слайдлар, иллюстрацияләр.

## Дәрес барышы

**I. Оештыру-мотивлаштыру**

Исәнләшү, уңай психологик халәт тудыру.

**II. Актуальләштерү**.

Хөрмәтле Дәреслекнең 87 биттә бирелгән табышмагына җавап эзләү, шуның аша укучыларны дәрестә эшләргә кызыксындыру.

**III. Уку мәсьәләсен кую**.

Укучылар дәрестә үтелгәннәрне гомумиләштереп кабатлаячакларын фаразлыйлар.

**IV. Белемнәрне ныгыту**.

Дәреслектә тәкъдим ителгән сорауларга җавап бирү. Бу вакытта «Сәламәт яшибез, спорт белән шөгыльләнәбез» темасы кысаларында өйрәнелгәннәр искә төшерелә, белемнәр ныгытыла. Ахырдан проблемалы сорау бирелеп, аңа җавапны фаразлап, сыйныф белән эшләү күздә тотыла.

Укучыларга Хөрмәтле Дәреслекнең оештырган уены кызыклы булачак. Биредә *сәламәтлек* сүзендәге хәрефләрдән сүзләр төзү сорала.

Гөлназның китапханәсендәге китапларны карау, алар турында мәгълүмат биреп, укуга кызыксыну уяту.

**V. Рефлексия.**

Дәрестә өйрәнелгәннәргә нәтиҗә ясала.

Бәяләү, үзбәя бирелә.

Учебное издание

**Мухарлямова** Гульназ Нурфатовна
**Абдуллина** Дилария Маратовна

**ЛИТЕРАТУРНОЕ ЧТЕНИЕ**

**3 класс**

Методическое пособие
для преподавателей образовательных организаций
начального общего образования, работающих
с учащимися, изучающими татарский язык как родной

На татарском языке

Уку-укыту басмасы

**Мөхәрләмова** Гөлназ Нурфат кызы
**Абдуллина** Диләрия Марат кызы

**ӘДӘБИ УКУ**

**3 нче сыйныф**

Методик әсбап
Башлангыч гомуми белем бирү оешмаларында
татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар белән
эшләүче укытучылар өчен

Мөхәррире *Л.Г. Шәрифуллина*
Рәссамы *Д.Л. Нәүрузова*
Компьютерда биткә салучысы *Э.Ф. Нурмөхәммәтова*

Подписано в печать с оригинал-макета 10.04.2023.
Формат 60 x 84 1/16. Бумага офсетная.